**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 12 маендагы 1421 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2018 елның 26 декабрендәге 6498 номерлы**
**«Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләре**
**хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы**
**карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүнең оклад системасын кертү чаралары планын гамәлгә ашыру кысаларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 31 маендагы 413 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы карарын (аңа Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 30 декабрендәге 1245 номерлы, 2021 елның 26 июлендәге 645 номерлы, 2021 елның 30 октябрендәге 1030 номерлы, 2022 елның 19 февралендәге 141 номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 566 номерлы, 2024 елның 24 маендагы 361 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) үтәү йөзеннән **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 26 декабрендәге 6498 номерлы «Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 2 декабрендәге 4171 номерлы, 2022 елның 16 декабрендәге 4382 номерлы, 2023 елның 5 июнендәге 1565 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 1 - 8 номерлы кушымталарын гамәлдән чыккан дип танырга;

1.2. әлеге карарның 1 - 8 номерлы кушымталарын тиешле тәртиптә Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 26 декабрендәге 6498 номерлы карарының 1 - 8 номерлы кушымталары дип санарга.

2. Әлеге карарның йогынтысы 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 12 маендагы
1421 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәре муниципаль китапханәләренең, музейларының, музей тибындагы башка учреждениеләренең һәм мәдәни-ял итү учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Казан шәһәре муниципаль китапханәләренең, музейларының, музей тибындагы башка учреждениеләренең һәм мәдәни-ял итү учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы әлеге нигезләмә (алга таба – Нигезләмә, мәдәният хезмәткәрләре) хезмәткәрләрнең окладларын формалаштыру тәртибен, стимуллаштыру һәм компенсация характерындагы түләүләр шартларын һәм күләмнәрен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын гамәлгә кертә.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

- хезмәт өчен түләү системасы - төп окладларның, вазифаи окладларның күләмнәрен кертеп, мәдәният хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү шартларын һәм күләмнәрен билгели торган нормалар җыелмасы, шулай ук федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән стимуллаштыру һәм компенсация характерындагы түләүләр;

- төп оклад – компенсация һәм стимуллаштыру түләүләрен исәпкә алмыйча, тиешле һөнәри квалификация төркеменә керә торган эшче һөнәре яисә җитәкче, белгеч, техник башкаручы вазифасы буенча һөнәри эшчәнлек башкаручы мәдәният хезмәткәренең оклады;

- вазифаи оклад – компенсация һәм стимуллаштыру түләүләрен исәпкә алмыйча, ставканы исәпкә алып, календарь ай өчен тиешле катлаулылыктагы хезмәт (вазифаи) бурычларын үтәгән өчен мәдәният хезмәткәренең хезмәтенә түләүнең билгеләнгән күләме;

- хезмәт хакы (хезмәткәрнең хезмәте өчен түләү) – мәдәният хезмәткәренең

квалификациясенә, башкарыла торган эшнең катлаулылыгына, күләменә, сыйфатына һәм шартларына карап, хезмәт өчен түләү, шулай ук компенсация һәм стимуллаштыру түләүләре;

- стимуллаштыру характерындагы түләүләр – стимуллаштыру сыйфатында өстәп һәм өстәмә түләүләр, премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре.

- компенсация характерындагы түләүләр – компенсация характерындагы, шул исәптән нормага туры килмәгән шартларда эшләгән өчен өстәп һәм өстәмә түләүләр һәм компенсация характерындагы башка түләүләр.

1.3. Мәдәният хезмәткәренең хезмәт хакы (хезмәте өчен түләү) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

- окладлардан (вазифаи окладлар), хезмәт хакы ставкаларыннан;

- стимуллаштыру характерындагы түләүләрдән;

- компенсация характерындагы түләүләрдән.

1.4. Мәдәният хезмәткәренең профиль буенча эш стажы артуга, квалификация категориясе бирелүгә, мактаулы исем бирелүгә бәйле рәвештә, еллык яки башка ялда булу вакытында, вакытлыча хезмәткә яраксызлык чорында, шулай ук уртача хезмәт хакы саклана торган башка чорларга бәйле рәвештә хезмәтенә түләү күләме үзгәрүгә хокукы барлыкка килсә, аның хезмәтенә түләү күләме күрсәтелгән чорлар тәмамланганнан соң үзгәртелә.

1.5. Казан шәһәренең муниципаль китапханә, музейлар, музей тибындагы башка учреждениеләр һәм мәдәни-ял итү учреждениеләре җитәкчеләре:

- белем турында һәм эш стажы (белгечлек буенча, билгеле бер вазифада эшләү) турында документларның Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2011 елның 30 мартындагы 251н номерлы «Җитәкчекләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазифаларының бердәм квалификация белешмәлеген раслау турында, «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифаларының квалификация характеристикалары» бүлеге» әмере белән билгеләнгән квалификация характеристикаларына туры килү-килмәвен тикшерәләр;

- ел саен барлык мәдәният хезмәткәрләренә тарификация исемлекләрен төзиләр һәм раслыйлар;

- мәдәният хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмен вакытында һәм дөрес билгеләү өчен җавап бирәләр.

## II. Мәдәният хезмәткәрләренең төп окладларын билгеләү

2.1. Мәдәният хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Вазифа атамасы** | **Бер айга төп оклад күләме, сумнарда** |
|---|---|
| «Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Билет тикшерүчеләр | 23 008 |
| Музей күзәтүчесе | 23 008 |
| «Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Аккомпаниатор | 25 700 |
| Оркестрның (ансамбльнең) кинотеатрларга, ресторannнарга, кафеларга һәм бию мәйданчыкларына хезмәт күрсәтүче артисты | 25 700 |
| Режиссер, дирижер, балетмейстер, хормейстер ассистентлары | 25 700 |
| Дискотека алып баручы | 25 700 |
| Билет кассалары мөдире | 25 700 |
| Костюмнар бүлмәсе мөдире | 25 700 |
| Аттракционда контролер-утыртучы | 25 700 |
| Мәдәни чаралар оештыручы | 25 700 |
| Фильмнар фондын ремонтлау һәм реставрацияләү участогы мастеры | 25 700 |
| Экскурсияләр оештыручы | 25 700 |
| Режиссер ярдәмчесе | 25 700 |
| Бию кичәсен оештыручы | 25 700 |
| Түгәрәк, һәвәскәр берләшмә, кызыксынулар буенча клуб җитәкчесе | 25 700 |
| «Әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Администратор | 26 000 |
| Администратор (өлкән администратор) | 26 000 |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| Вазифа атамасы | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда |
|---|---|
| Аккомпаниатор-концертмейстер | 26 000 |
| Оркестр артисты | 26 000 |
| Артист-вокалист (солист) | 26 000 |
| Библиограф | 26 000 |
| Китапханәче | 26 000 |
| Алып баручы библиограф | 26 000 |
| Әйдәүче китапханәче | 26 000 |
| Китапханәнең, музейның һәм башка шундый учреждениеләрнең һәм оешмаларның әйдәүче методисты | 26 000 |
| Баш библиограф | 26 000 |
| Баш китапханәче | 26 000 |
| Аттракцион мөдире | 26 000 |
| Тавыш операторы | 26 000 |
| Кинооператор | 26 000 |
| Лектор (экскурсияләр алып баручы) | 26 000 |
| Китапханә, музей һәм башка шундый учреждениеләр һәм оешмалар методисты | 26 000 |
| Клуб учреждениесе, халык иҗаты фәнни-методик үзәге, халык иҗаты йорты, халык мәдәнияте үзәге (мәдәният һәм ял итү) һәм башка шундый учреждениеләр һәм оешмалар методисты | 26 000 |
| Кинопрограммалар төзү методисты | 26 000 |
| Мөхәррир (музыкаль мөхәррир) | 26 000 |
| Китапханә, музей һәм башка шундый учреждениеләр һәм оешмалар мөхәррире | 26 000 |
| Клуб учреждениесе, халык иҗаты фәнни-методик үзәге, халык иҗаты йорты, халык мәдәнияте үзәге (мәдәният һәм ял итү) һәм башка шундый учреждениеләр һәм | 26 000 |

| Вазифа атамасы | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда |
|---|---|
| оешмалар мөхәррире | |
| Репертуар мөхәррире | 26 000 |
| Иҗат жанрлары буенча белгеч | 26 000 |
| Клуб эше методикасы буенча белгеч | 26 000 |
| Исәп-саклау документлары буенча белгеч | 26 000 |
| Фольклор белгече | 26 000 |
| Экспозиция һәм күргәзмә бүлеге белгече | 26 000 |
| Фондларны саклаучы | 26 000 |
| Ут буенча рәссам | 26 000 |
| Рәссам-декоратор | 26 000 |
| Рәссам-конструктор | 26 000 |
| Рәссам-бизәүче | 26 000 |
| Куючы рәссам | 26 000 |
| Рәссам-реставратор | 26 000 |
| Сынчы рәссам | 26 000 |
| Рәссам-фотограф | 26 000 |
| «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Куючы балетмейстер | 26 300 |
| Фондларның төп саклаучысы | 26 300 |
| Баш рәссам | 26 300 |
| Зоопаркның ветеринария лабораториясе мөдире | 26 300 |
| Кино- һәм видеофильмнар прокаты бүлеге (пункты) мөдире | 26 300 |
| Китапханәнең бүлек (сектор) мөдире | 26 300 |
| Мәдәният йорты (сарае), мәдәният һәм ял паркы, халык | 26 300 |

| Вазифа атамасы | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда |
|---|---|
| иҗаты буенча фәнни-методик үзәк, халык иҗаты йорты, халык мәдәнияте (мәдәният һәм ял итү) үзәге һәм башка шундый учреждениеләр һәм оешмалар бүлеге (секторы) мөдире | |
| Зоопарктагы бүлек (сектор) мөдире | 26 300 |
| Музей бүлеге (секторы) мөдире | 26 300 |
| Аттракцион техникасын эшләтү бүлеге мөдире | 26 300 |
| Музейның күчмә күргәзмәсе мөдире | 26 300 |
| Реставрация остаханәсе мөдире | 26 300 |
| Сәнгатьчә бизәү остаханәсе мөдире- | 26 300 |
| Тавыш режиссеры | 26 300 |
| Режиссер (дирижер, балетмейстер, хормейстер) | 26 300 |
| Массакүләм тамашалар режиссеры | 26 300 |
| Куючы режиссер | 26 300 |
| Клуб берләшмәсе, һәвәскәрләр берләшмәсе, студия, үзешчән сәнгать коллективы, кызыксынулар буенча клуб җитәкчесе | 26 300 |
| Сәнгать җитәкчесе | 26 300 |

2.2. «Әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары» һәм «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазифалары» һөнәри квалификация төркемнәренә кертелмәгән мәдәния хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Һөнәри стандарт нигезендә вазифа атамасы | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда |
|---|---|
| Музей предметларын саклаучы | 26 000 |
| Музей предметларын исәпкә алу белгече | 26 000 |
| Экскурсовод | 26 000 |

| | |
|---|---|
| Гид-тәрҗемәче | 26 000 |
| Баш саклаучы | 26 300 |
| Музейның исәп бүлеге (секторы) мөдире | 26 300 |

«Музей бүлеге (секторы) мөдире», «музей исәбе бүлеге (секторы) мөдире», «китапханәнең бүлек (секторы) мөдире», «китапханәнең бүлек (секторы) мөдире», «мәдәният йорты (сарае) бүлеге (секторы), мәдәният һәм ял паркы, халык иҗаты буенча фәнни-методик үзәге, халык иҗаты йорты, халык мәдәнияте үзәге (мәдәният һәм ял итү) һәм башка шундый ук учреждениеләр, зоопарк бүлеге (секторы) мөдире», «кино һәм видеофильмнар прокаты буенча бүлек (пункт) мөдире» һәм «сәнгать җитәкчесе» вазифалары буенча өстәмә рәвештә база окладына арттыру коэффициенты кулланыла – 1,1.

## III. Мәдәният хезмәткәрләренең вазифаи окладларын формалаштыру тәртибе

Мәдәният хезмәткәрләренең вазифаи оклады ($O_d$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times S,$$ монда:

$O_b$ – мәдәният хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган төп окладлы;

S – мәдәният хезмәткәре биләп торган ставкаларның факттагы саны.

## IV. Кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр

4.1. Стимуллаштыру характерындагы түләүләргә хезмәткәрне хезмәтнең сыйфат нәтиҗәсенә стимуллаштыруга, шулай ук башкарылган эш өчен кызыксындыруга юнәлдерелгән түләүләр керә.

4.2. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр;
- квалификация категориясе өчен түләүләр;
- профиль буенча эш стажы өчен түләүләр;
- башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре;
- премия һәм башка кызыксындыру түләүләре.

4.3. Мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр ($B_{pz}$) мәдәният, сәнгать һәм

кинематография хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче хезмәткәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%}, \text{ монда:}$$

$O_d$ – мәдәният хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{pz}$ – мактаулы исемнәр булган өчен өстәмә түләү күләме.

4.4. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 8 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 10 процент тәшкил итә.

Стимуллаштыру сыйфатындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикаларның мактаулы исемнәре исемлеге әлеге Нигезләмәнең кушымтасында китерелгән.

4.5. Мактаулы исемнәр алган өчен түләү күләмнәрен билгеләү мактаулы исем бирелгән көннән билгеләнә. Ике һәм аннан күбрәк мактаулы исемнәре булган хезмәткәрләргә мактаулы исемнәре булган өчен түләү хезмәткәр сайлаган бер мактаулы исем буенча билгеләнә.

4.6. Квалификация категориясе өчен түләүләр ($B_{kk}$), һөнәри квалификация төркемнәреннән чыгып, аттестация йомгаклары буенча тариф-квалификация характеристикалары нигезендә квалификация категорияләре бирүне күз алдында тота торган белгечлекләр буенча эшләүче мәдәният хезмәткәрләренә бирелә.

Квалификация категориясе өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%}, \text{ монда:}$$

$O_d$ – мәдәният хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{kk}$ – квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме.

Квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләмнәре 1 нче таблицада китерелгән.

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясе төзелгән орган (учреждение) әмере датасы буенча башкарыла.

1 таблица

**Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме**

| **Квалификация категориясе** | **Өстәмә түләүләр күләме, процентларда** |
|---|---|
| Алдынгы звено мәдәният хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | |
| 2 нче квалификация категориясе | 2 |
| 1 нче квалификация категориясе | 4 |
| Югары квалификация категориясе, шулай ук исемендә «баш» яки «әйдәүче» сүзләре булган вазифалар | 6 |

4.7. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр ($B_s$), профиль буенча эшнең дәвамлылыгыннан чыгып, һөнәри квалификация төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},\ \text{монда:}$$

$O_d$ – мәдәният хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_s$ – профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме.

Профиль буенча стаж өчен өстәмә түләүләр күләме 2 нче таблицада китерелгән.

2 нче таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме**

| **Һөнәри квалификация төркеме исеме** | **Стаж буенча төркем** | **Өстәмә түләүләр күләме, процентларда** |
|---|---|---|
| Урта звенога караган мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары | 3 елдан 10 елга кадәр | 12 |
| | 10 елдан 15 елга | 14 |

| | | |
|---|---|---|
| | кадәр | |
| | 15 елдан 20 елга кадәр | 16 |
| | 20 елдан 25 елга кадәр | 18 |
| | 25 елдан артык | 22 |
| Әйдәүче звенога караган мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары | 3 елдан 10 елга кадәр | 12 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 14 |
| | 15 елдан 20 елга кадәр | 16 |
| | 20 елдан 25 елга кадәр | 18 |
| | 25 елдан артык | 22 |
| Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазифалары | 3 елдан 10 елга кадәр | 12 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 14 |
| | 15 елдан 20 елга кадәр | 16 |
| | 20 елдан 25 елга кадәр | 18 |
| | 25 елдан артык | 22 |

4.8. Эшләү вакыты вазифа буенча эш стажына кертелә торган вазифалар (һөнәрләр) исемлеге Татарстан Республикасы мәдәният министры әмере белән раслана.

4.9. Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләме, әгәр стажны раслый торган документлар учреждениедә булса, профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкән көннән алып яисә стажны раслый торган кирәкле документ тапшырылган көннән алып билгеләнә (үзгәртелә).

4.10. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре

мәдәният хезмәткәрләренә билгеле бер вакыт аралыгында (бер ай, квартал, бер ел) хезмәт нәтиҗәләре буенча билгеләнә. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре күләменә йогынты ясый торган төп критерий булып Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе башлыгы әмере белән раслана торган мәдәният хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының чик күрсәткечләренә ирешү тора.

4.11. Мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары аларның җитәкчеләре тарафыннан раслана. Мәдәният хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының конкрет билгеләре һәм түләүләр башкару шартлары, учреждение алдында торган бурычлардан чыгып, ел саен билгеләнә.

4.12. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре бирү күләме, тәртибе һәм шартлары учреждениенең локаль норматив хокукый актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнә.

4.13. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре ($B_k$) һөнәри квалификация төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_k = O_d \times \frac{D_k}{100\%}, \text{ монда:}$$

$O_d$ – мәдәният хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_k$ – башкарыла торган эшләр сыйфаты өчен өстәмә түләүнең чик күләме.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмә түләүләрнең чик күләме 3 нче таблицада китерелгән.

3 нче таблица

**Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмә түләүләрнең чик күләмнәре**

| **Һөнәри квалификация төркеме исеме** | **Өстәмә түләүләр күләме, процентларда** |
|---|---|
| Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазифалары | 14 |
| Урта звенога караган мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары | 22 |
| Әйдәүче звенога караган мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары | 32 |

| Һөнәри квалификация төркеме исеме | Өстәмә түләүләр күләме, процентларда |
|---|---|
| Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазифалары | 42 |

4.14. Премия һәм башка кызыксындыру түләүләре хезмәткәрләргә юбилей даталары, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алу белән бәйле рәвештә һәм учреждениеләрнең локаль норматив актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнгән башка нигезләр буенча билгеле бер чор (ай, квартал, ел) өчен бер тапкыр билгеләнә.

4.15. Мәдәният хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында»гы Указы белән билгеләнгән максатчан күрсәткечләрнең ирешелгән дәрәҗәсен саклап калу максатыннан төп эш урыны һәм төп вазифа буенча мәдәният өлкәсе хезмәткәрләренә, акча булган очракта, бер тапкыр бүләкләү түләве бирелә. Күрсәтелгән максатларда түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме учреждениенең локаль норматив актлары белән билгеләнә.

4.16. Премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләрен башкару күләме, тәртибе һәм шартлары учреждениенең локаль норматив хокукый актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнә.

## V. Учреждение җитәкчесенең, учреждение җитәкчесе урынбасарының, баш бухгалтерның хезмәт хакын билгеләү тәртибе

5.1. Учреждение җитәкчесенең, учреждение җитәкчесе урынбасарының, баш бухгалтерның хезмәт хакы вазифаи окладлардан һәм стимуллаштыру һәм компенсация сыйфатындагы түләүләрдән тора.

5.2. Мәдәният учреждениесе җитәкчесенең окладлы, хезмәт өчен түләү төркеменә карап, мәдәният учреждениесен гамәлгә куючы тарафыннан елына бер тапкыр билгеләнә. Мәдәният учреждениесе җитәкчесенең хезмәт өчен түләү төркеме мәдәният учреждениесе хезмәткәрләренең штат санына карап билгеләнә.

5.3. Учреждение җитәкчеләре урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының окладлары әлеге учреждение җитәкчеләренең вазифаи окладларыннан 20-30 процентка түбәнрәк билгеләнә.

5.4. Җитәкчеләр хезмәте өчен түләү төркеме, җитәкчеләрнең хезмәт хакы

күләмнәре 4 нче таблицада китерелгән.

4 нче таблица

**Мәдәният учреждениеләре җитәкчеләренең окладлары**

| Учреждение төре | Айлык оклад күләме, мең сумнарда | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хезмәт өчен түләү төркеме | | | | | | | |
| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | Хезмәткәрләрнең штат саны, ставкалар саны | | | | | | | |
| | 10,999 га кадәр | 11 дән 30,999 га кадәр | 31 дән 50,999 га кадәр | 51 дән 75,999 га кадәр | 76 дан 150,999 га кадәр | 151 дән 300,999 га кадәр | 301 дән 500,999 га кадәр | 501 дән артык |
| Китапханәләр | - | 35,0 | 42,0 | 45,5 | 49,0 | 57,0 | 62,0 | - |
| Клублар | 33,0 | 39,5 | 42,0 | 45,5 | 47,0 | 52,0 | 62,0 | - |
| Музейлар | 34,5 | 38,5 | 40,0 | 47,0 | 49,0 | 57,0 | 62,0 | - |
| Мәдәни-ял итү үзәге | - | 44,0 | 45,0 | 47,0 | - | - | - | - |
| Җирле радиотапшырулар | 32,0 | - | - | - | - | - | - | - |
| Кино-, видеоберләшмә | 30,0 | 35,0 | - | - | - | - | - | - |
| Башкалар | 30,0 | 45,0 | - | 46,0 | 47,0 | - | - | - |

5.5. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр мәдәният учреждениесе җитәкчесенә, эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, мәдәният учреждениесен гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Мәдәният учреждениесе җитәкчесенә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр ай саен, бер еллык эш нәтиҗәләре буенча, әһәмиятле һәм аеруча әһәмиятле йөкләмәләрне үтәгән өчен бирелергә мөмкин.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен мәдәният учреждениесе җитәкчесенә кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр күләме 5 нче таблицада бирелгән.



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

5 таблица

**Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен мәдәният учреждениеләре җитәкчеләренә кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр күләме**

| Учреждение төре | Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен бер айга кызыксындыру характерындагы түләү күләме, мең сумнарда | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хезмәт өчен түләү төркеме | | | | | | | |
| | Хезмәткәрләрнең штат саны, ставкалар саны | | | | | | | |
| | 10,999 га кадәр | 11 дән 30,999 га кадәр | 31 дән 50,999 га кадәр | 51 дән 75,999 га кадәр | 76 дан 150,999 га кадәр | 151 дән 300,999 га кадәр | 301 дән 500,999 га кадәр | 501 дән артык |
| Китапханәләр | - | 4,0 | 5,0 | 5,5 | 6,5 | 7,0 | 7,0 | - |
| Клублар | 3,5 | 4,5 | 5,0 | 5,5 | 6,0 | 6,5 | 7,0 | - |
| Музейлар | 3,5 | 4,0 | 4,5 | 6,0 | 6,5 | 7,0 | 7,0 | - |
| Мәдәни-ял итү үзәге | - | 5,0 | 5,5 | 6,0 | - | - | - | - |
| Җирле радиотапшырулар | 3,0 | - | - | - | - | - | - | - |
| Кино-, видеоберләшмә | 3,0 | 4,0 | - | - | - | - | - | - |
| Башкалар | 3,0 | 5,5 | - | 6,0 | 6,0 | - | - | - |

5.6. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен мәдәният учреждениесендәге җитәкче урынбасарына, баш бухгалтерга кызыксындыру характердагы түләүләр, аларның эшчәнлеге нәтиҗәләрен исәпкә алып, локаль норматив актларда билгеләнгән нәтиҗәлелек критерийлары нигезендә билгеләнә. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен җитәкче урынбасарына, баш бухгалтерга кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр ай саен, бер еллык эш нәтиҗәләре буенча, әһәмиятле һәм аеруча әһәмиятле йөкләмәләрне үтәгән өчен бирелергә мөмкин. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен җитәкче урынбасарына, баш бухгалтерга кызыксындыру характерындагы түләүнең чик дәрәҗәсе башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен мәдәният учреждениесе җитәкчесенә кызыксындыру характерында түләнә торган түләүләрнең 80 проценты дәрәҗәсендә билгеләнә.

5.7. Мәдәният учреждениесенең җитәкчеләре, җитәкче урынбасарлары һәм

баш бухгалтерлары эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең типлаштырылган критерийлары һәм аларның авырлык коэффициентлары мәдәният учреждениесен гамәлгә куючы тарафыннан раслана.

5.8. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр ($B_k$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_k = B_c \times K_{vk}$$, монда:

$B_c$ – Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен мәдәният учреждениесе җитәкчесенә кызыксындыру сыйфатындагы түләүләрнең 5 нче таблицада билгеләнгән күләме.

$K_{vk}$ – сыйфат критерийларын үтәү коэффициенты.

5.9. Мәдәният учреждениеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү һәм 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында»гы Россия Федерациясе Президенты Указы белән билгеләнгән максатчан күрсәткечләрне ирешелгән дәрәҗәдә саклап калу максатыннан, төп эш урыны буенча һәм төп вазифа буенча мәдәният учреждениеләре җитәкчеләренә, учреждение җитәкчеләре урынбасарларына һәм баш бухгалтерларга, акча булган очракта, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү башкарыла. Күрсәтелгән максатлардагы түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме мәдәният учреждениесен гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

5.10. Компенсация сыйфатындагы түләүләр муниципаль мәдәният учреждениеләре җитәкчеләре, аларның урынбасарлары һәм баш бухгалтерлары өчен Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә раслана торган компенсация сыйфатындагы түләү төрләре исемлеге нигезендә билгеләнә.

## VI. Компенсация сыйфатындагы түләүләр

6.1. Компенсация сыйфатындагы түләүләргә түбәндәгеләр керә:

- эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр;

- зарарлы һәм (яисә) куркыныч һәм башка махсус хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә түләүләр;

- нормаль шартлардан читләшкән шартларда (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазифаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен, төнлә эшләгән һәм нормаль шартлардан читләшкән башка шартларда эшләр башкарганда) эшләгән өчен түләүләр.

6.2. Компенсация сыйфатындагы түләүләр, аларны башкару күләмнәре һәм шартлары хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган хезмәт законнары һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә коллектив шартнамәләр, килешүләр,

локаль норматив актлар белән һәм Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләренең хезмәткә түләүнең расланган фонды чикләрендә билгеләнә.

6.3. Эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр ($B_{sd}$) аерым учреждениеләрдә урта, әйдәүче звено һәм җитәкче состав вазифаларының мәдәният, сәнгать һәм кинематография һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sd} = O_d \times \frac{D_{sd}}{100\%},$$ монда:

$O_d$ – мәдәният хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{sd}$ – эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләү күләме.

Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләү күләмнәре 6 нчы таблицада китерелгән.

6 нчы таблица

**Эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләрнең тәкъдим ителә торган күләме**

| **№ т/б** | **Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләү билгеләүнең нигезе** | **Һөнәри квалификация төркеме исеме** | **Өстәмә түләүләр күләме, процентларда** |
|---|---|---|---|
| 1 | Физик үсеш ягыннан җитешсезлекләре булган (сукыр, саңгырау) затларга хезмәт күрсәтү | Урта звенога караган мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары | 5 |
| | | Әйдәүче звенога караган мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары | 5 |
| 2 | Милли статусы булган мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләрендә эшләү | Әйдәүче звенога караган мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары | 30 |
| | | Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазифалары | 30 |

| № т/б | Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләү билгеләүнең нигезе | Һөнәри квалификация төркеме исеме | Өстәмә түләүләр күләме, процентларда |
|---|---|---|---|
| 3 | Чит телне гамәли эштә куллану | Әйдәүче звенога караган мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары | 5 |
| | | Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазифалары | 5 |

6.4. Әлеге учреждениедә, бүлекчәдә һәм вазифада конкрет эш шартларын исәпкә алып, эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләр билгеләнә торган мәдәният хезмәткәрләре вазифалары исемлеге, сайлана торган профсоюз органы яки мәдәният хезмәткәрләренең мәнфәгатьләрен якларга вәкаләтле башка орган белән килештереп, һәр учреждение тарафыннан раслана.

6.5. Зарарлы һәм (яки) куркыныч һәм башка махсус хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче мәдәният хезмәткәрләренә компенсация сыйфатындагы түләү ($_{Bkh}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = O_b \times \frac{D_{kh}}{100\%} \times \frac{H_{fk}}{H_n}, \text{ монда:}$$

$O_b$ – мәдәният хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган төп оклады;

$D_{kh}$ – компенсация сыйфатындагы түләүгә өстәмә түләү күләме;

$H_{fk}$ – законнар белән компенсация сыйфатындагы түләүләр карала торган, фактта эшләнгән вакыт, сәгатьләрдә;

$H_n$ – мәдәният хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган төп ставкасы (төп оклады) өчен сәгатьләр нормасы.

Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартларында эшләүче мәдәният хезмәткәрләренә эшләгән өчен компенсация сыйфатындагы түләүләр хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә 4 процент күләмендә билгеләнә.

6.6. Нормаль шартларга туры килмәгән шартларда эшләгән өчен (төрле квалификация буенча эшләр башкарганда, һөнәрләрне (вазифаларны)


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен, төнлә эшләгән өчен һәм нормаль шартларга туры килмәгән башка шартларда эшләр башкарганда) түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә.

## VII. Муниципаль китапханәләрнең, музейларның, музей тибындагы башка учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял итү учреждениеләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру һәм куллану тәртибе

7.1. Муниципаль китапханәләрнең, музейларның, музей тибындагы башка учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял итү учреждениеләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру норматив чыгымнар, кулланучылар һәм хезмәт күрсәтүләр саны нигезендә билгеләнгән агымдагы финанс елына мәдәният учреждениесе акчалары күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм мәдәният учреждениесенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагыла.

7.2. Әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән вазифаи окладларны, кызыксындыру һәм компенсация характерындагы түләүләрне исәпләү муниципаль китапханәләрнең, музейларның, музей тибындагы башка учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял итү учреждениеләренең барлык хезмәткәрләренә агымдагы финанс елына хезмәт өчен түләүгә мәдәният учреждениесенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында каралган акчалар хисабына башкарыла.

7.3. Барлык түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, муниципаль китапханәләрнең, музейларның, музей тибындагы башка учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял итү учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында барлыкка килгән хезмәт өчен түләү фондын финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары хисабына тиешле период өчен (ай, квартал, ел) экономияләнгән акчалар, Казан шәһәренең муниципаль китапханәләре, музейлары, музей тибындагы башка учреждениеләре һәм мәдәни-ял итү учреждениеләренең әлеге Нигезләмәнең нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру түләүләренә җибәрелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фонды экономияләнгәндә, кызыксындыру түләүләре, хезмәт өчен түләү фондында вазифаларның кайсы һөнәри-квалификация төркемендә экономия барлыкка килгән, шул төркем хезмәткәрләргә түләнә.

Казан шәһәренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре, фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре һөнәрләре, гомумтармак эшче һөнәрләре, гомумтармак җитәкче, белгеч һәм хезмәткәр вазифалары, авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре, мәгариф хезмәткәрләре, медицина һәм фармацевтика

хезмәткәрләре, муниципаль китапханәләр, музейлар, музей тибындагы башка учреждениеләр һәм мәдәни-ял итү учреждениеләре хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә, шул чорда үтәлгән эш вакыты нормаларын (хезмәт бурычларын) исәпкә алып, тиешле чор өчен хезмәткә түләү фондын экономияләү хисабына башкарылган кызыксындыру түләвенең күләме агымдагы елның 1 гыйнварына 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында»гы федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен минималь түләү күләменнән өч тапкырдан да артмаска тиеш.

Казан шәһәренең муниципаль китапханәләр, музейлар, музей тибындагы башка учреждениеләр һәм мәдәни-ял учреждениеләре җитәкчеләренә хезмәт өчен түләү фондын экономияләү исәбенә кызыксындыру түләүләре күләме мәдәният учреждениесен гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, барлык финанс белән тәэмин итү чыганаклары хисабына муниципаль китапханәләрнең, музейларның, музей тибындагы башка учреждениеләрнең һәм музей тибындагы мәдәни-ял итү учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында барлыкка килгән, хезмәткә түләү фондынан экономияләнгән акчадан файдаланган өчен җаваплылык Казан шәһәренең муниципаль китапханәләр, музейлар, музей тибындагы башка учреждениеләр һәм мәдәни-ял учреждениеләре җитәкчеләренә йөкләнә.

_______________

Казан шәһәре муниципаль китапханәләренең, музейларының, музей тибындагы башка учреждениеләренең һәм мәдәни-ял учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә кушымта

**Кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикаларның мактаулы исемнәре исемлеге**

| № т/б | Мактаулы исемнең, дәүләт бүләгенең аталышы |
|---|---|
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1 | Россия Федерациясенең халык артисты |
| 1.2 | Россия Федерациясенең халык рәссамы |
| 1.3 | Россия Федерациясенең атказанган артисты |
| 1.4 | Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 1.5 | Россия Федерациясенең атказанган рәссамы |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 2.1 | Татарстан Республикасының халык артисты |
| 2.2 | Татарстан Республикасының халык язучысы |
| 2.3 | Татарстан Республикасының халык шагыйре |
| 2.4 | Татарстан Республикасының халык рәссамы |

| №<br>т/б | Мактаулы исемнең, дәүләт бүләгенең аталышы |
|---|---|
| 2.5 | Татарстан Республикасының атказанган артисты |
| 2.6 | Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 2.7 | Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре |
| | 3. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре |
| 3.1 | СССРның халык артисты |
| 3.2 | СССРның халык рәссамы |
| | 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре |
| 4.1 | Атказанган пропагандачы |
| 4.2 | Халык артисты |
| 4.3 | Атказанган артист |
| 4.4 | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 4.5 | Халык рәссамы |
| 4.6 | Атказанган рәссам |
| 4.7 | Халык язучысы |
| 4.8 | Атказанган язучы |
| 4.9 | Халык шагыйре |
| 4.10 | Халык җырчысы |
| 4.11 | Халык акыны |
| 4.12 | Атказанган журналист |
| 4.13 | Атказанган мәдәният эшлеклесе |
| 4.14 | Атказанган мәдәни-мәгърифәтчелек эше хезмәткәре |
| 4.15 | Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 4.16 | Атказанган китапханәче |
| 4.17 | Гамәли сәнгать остасы |

| № т/б | Мактаулы исемнең, дәүләт бүләгенең аталышы |
|---|---|
| 4.18 | Атказанган халык иҗаты остасы |
| 4.19 | Атказанган фән эшлеклесе |
| 5. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автономияле республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 5.1 | Атказанган төзүче |
| 5.2 | Халык артисты |
| 5.3 | Атказанган артист |
| 5.4 | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 5.5 | Халык рәссамы |
| 5.6 | Атказанган рәссам |
| 5.7 | Халык язучысы |
| 5.8 | Атказанган язучы |
| 5.9 | Халык шагыйре |
| 5.10 | Атказанган журналист |
| 5.11 | Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 5.12 | Атказанган китапханәче |
| 5.13 | Атказанган фән һәм мәдәният эшлеклесе |
| 5.14 | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 5.15 | Атказанган фән эшлеклесе |

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 12 маендагы
1421 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең башкару сәнгатенә караган муниципаль учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Казан шәһәренең башкару сәнгатенә караган муниципаль учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы әлеге нигезләмә (алга таба – Нигезләмә, башкару сәнгате хезмәткәрләре) хезмәткәрләрнең окладларын формалаштыру тәртибен, кызыксындыру һәм компенсация характерындагы түләүләрнең шартларын һәм күләмен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын билгели.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

- хезмәт өчен түләү системасы – төп окладларның, вазифаи окладларның күләмнәрен, шулай ук федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән компенсация һәм кызыксындыру сыйфатындагы түләүләрне дә кертеп, башкару сәнгате хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартларын һәм күләмнәрен билгели торган нормалар җыелмасы;

- төп оклад – компенсация һәм кызыксындыру түләүләрен исәпкә алмыйча, тиешле һөнәри квалификация төркеменә керә торган эшче һөнәре яисә җитәкче, белгеч, техник башкаручы вазифасы буенча һөнәри эшчәнлек башкаручы башкару сәнгате хезмәткәренең оклады;

- вазифаи оклад – компенсация һәм кызыксындыру түләүләрен исәпкә алмыйча, ставканы исәпкә алып, календарь ай өчен тиешле катлаулылыктагы хезмәт (вазифаи) бурычларын үтәгән өчен башкару сәнгате хезмәткәренең хезмәтенә түләүнең билгеләнгән күләме;

- хезмәт хакы (хезмәткәрнең хезмәте өчен түләү) – башкару сәнгате

хезмәткәренең квалификациясенә, башкарыла торган эшнең катлаулылыгына, күләменә, сыйфатына һәм шартларына карап, хезмәт өчен түләү, шулай ук компенсация һәм кызыксындыру түләүләре;

- компенсация сыйфатындагы түләүләр – нормага туры килмәгән шартларда эшләгән өчен түләүләрне дә кертеп, компенсация сыйфатындагы өстәп һәм өстәмә түләүләр һәм компенсация сыйфатындагы башка түләүләр;

- кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр – кызыксындыру сыйфатындагы өстәп һәм өстәмә түләүләр, премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре.

1.3. Башкару сәнгате хезмәткәрләренең хезмәт хакы (хезмәте өчен түләү) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

- окладлардан (вазифаи окладлар), хезмәт хакы ставкаларыннан;

- стимуллаштыру характерындагы түләүләрдән;

- компенсация характерындагы түләүләрдән.

1.4. Башкару сәнгате хезмәткәренең профиль буенча эш стажы артуга, квалификация категориясе бирелүгә, мактаулы исем бирелүгә бәйле рәвештә, еллык яки башка ялда булу вакытында, вакытлыча хезмәткә яраксызлык чорында, шулай ук уртача хезмәт хакы саклана торган башка чорларга бәйле рәвештә хезмәтенә түләү күләме үзгәрүгә хокукы барлыкка килсә, аның хезмәтенә түләү күләме күрсәтелгән чорлар тәмамланганнан соң үзгәртелә.

1.5. Казан шәһәренең башкару сәнгате муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре:

- белем турында һәм эш стажы (белгечлек буенча, билгеле бер вазифада эшләү) турында документларның Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2011 елның 30 мартындагы 251н номерлы «Җитәкчекләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазифаларының бердәм квалификация белешмәлеген раслау турында, «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифаларының квалификация характеристикалары» бүлеге» әмере белән билгеләнгән квалификация характеристикаларына туры килү-килмәвен тикшерәләр;

- башкару сәнгате муниципаль учреждениеләренең барлык хезмәткәрләренә ел саен тарификация исемлекләре төзиләр һәм раслыйлар;

- башкару сәнгате муниципаль учреждениеләренең барлык хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмен вакытында һәм дөрес билгеләү өчен җаваплы.

## II. Башкару сәнгате хезмәткәрләренең төп окладларын билгеләү

| Вазифа атамасы | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда |
|---|---|
| «Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Театрларның һәм концерт оешмаларының ярдәмче составы артисты | 23 008 |
| Циркта номер ассистенты | 23 008 |
| Билет тикшерүчеләр | 23 008 |
| «Урта звено башкару сәнгате хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | |
| Оркестрның (ансамбльнең) кинотеатрларга, рестораннарга, кафеларга һәм бию мәйданчыкларына хезмәт күрсәтүче артисты | 25 700 |
| Циркта дрессировщик | 25 700 |
| Билет кассалары мөдире | 25 700 |
| Суфлер | 25 700 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | |
| Цирк балеты артисты | 25 700 |
| Режиссер, дирижер, балетмейстер, хормейстер ассистентлары | 25 700 |
| Костюмнар бүлмәсе мөдире | 25 700 |
| Режиссер ярдәмчесе | 25 700 |
| Сөйләм техникасы буенча репетитор | 25 700 |
| «Әйдәүче звено башкару сәнгате хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | |
| Аккомпаниатор-концертмейстер | 26 000 |
| Музыкаль комедия (оперетта) театрларында, музыка-драма, драма театрларында, яшь тамашачы театрларында, курчак театрларында, циркларда хор артисты | 26 000 |

| Вазифа атамасы | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда |
|---|---|
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсенә караган администраторлардан тыш, администратор | 26 000 |
| Артист – һава гимнасты | 26 000 |
| «Эквилибр» жанры артисты | 26 000 |
| Хайваннарны дрессуралау жанры артисты | 26 000 |
| Жонглерлык жанры артисты | 26 000 |
| Иллюзия жанры артисты | 26 000 |
| Атларны дрессуралау жанры артисты | 26 000 |
| Келәмдә эшләүче артист, буффонада клоуны, музыкаль эксцентрик, сатирик | 26 000 |
| Җыр һәм бию ансамбльләре оркестры артисты | 26 000 |
| Спорт-акробатика жанры артисты | 26 000 |
| Опера һәм балет театрларында хор артисты | 26 000 |
| Эстрада оркестры (ансамбле) артисты – өченче-бишенче квалификация дәрәҗәләренә караган артистлардан тыш, оркестрның барлык артистлары | 26 000 |
| Ярдәмче составтагы концертларда башкаручы артистлардан тыш, концертларда башкаручы артистлар (барлык жанрлар) | 26 000 |
| Тавыш операторы | 26 000 |
| Репертуар мөхәррире | 26 000 |
| Балет буенча репетитор | 26 000 |
| Вокал буенча репетитор | 26 000 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | |
| Опера һәм балет театрларында, музыкаль комедия (оперетта) театрларында, музыкаль-драма, драма театрларында, яшь тамашачы театрларында, курчак театрларында, циркларда, концерт оешмаларында | 26 000 |

| Вазифа атамасы | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда |
|---|---|
| администратор, өлкән администратор | |
| Курчак театры артисты (курчак уйнатучы) | 26 000 |
| Балет артисты | 26 000 |
| Җыр һәм бию ансамбле балеты, бию коллективы артисты | 26 000 |
| Драма артисты | 26 000 |
| Оркестр артисты | 26 000 |
| Җыр һәм бию ансамбльләре оркестры артисты, эстрада оркестры (ансамбле) артисты – беренче скрипкалар һәм виолончельләрнең өченче һәм дүртенче пультлары, икенче скрипкалар, альтлар, контрабасларның икенче пульты, икенче флейта, икенче гобой, икенче кларнет, икенче фагот, икенче һәм дүртенче валторналар, икенче труба, икенче тромбон, вак бәрмә уен кораллары, икенче арфа, рояль, челеста | 26 000 |
| Симфоник, камера, эстрада-симфоник, тынлы оркестр, халык уен кораллары оркестры артисты, дүртенче һәм бишенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән тыш | 26 000 |
| Җыр һәм бию ансамбленең, хор коллективының хор артисты | 26 000 |
| Артист-вокалист (солист) | 26 000 |
| Манеж инспекторы (тамашаны алып баручы) | 26 000 |
| Вокал (балет) классы буенча концертмейстер | 26 000 |
| Мөхәррир (музыкаль мөхәррир) | 26 000 |
| Цирк номерлары репетиторы | 26 000 |
| Иҗат жанрлары буенча белгеч | 26 000 |
| Ут буенча рәссам | 26 000 |
| Рәссам-бутафор | 26 000 |
| Рәссам-гример | 26 000 |
| Рәссам-декоратор | 26 000 |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| Вазифа атамасы | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда |
|---|---|
| Рәссам-конструктор | 26 000 |
| Театр костюмы рәссам-модельеры | 26 000 |
| Куючы рәссам | 26 000 |
| Сынчы рәссам | 26 000 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | |
| Җыр һәм бию ансамбльләре оркестры артисты, эстрада оркестры (ансамбль) артисты – беренче скрипкалар, икенче скрипкалар, альтлар, виолончель, контрабаслар концертмейстеры һәм концертмейстеры урынбасары, әлеге уен коралларының икенче пульты, агач һәм бакыр тынлы инструментларның беренче тавышлары һәм аларны көйләгеч, беренче арфа, бас-тромбон, туба, литавралар | 26 000 |
| Симфоник, камера, эстрада-симфоник, тынлы оркестр артисты, халык уен кораллары оркестры артисты – беренче скрипкалар һәм виолончельләрнең өченче һәм дүртенче пультлары, икенче скрипка, альт, контрабас, икенче флейта, икенче гобой, икенче кларнет, икенче һәм дүртенче валторна, икенче труба, икенче тромбон, вак бәрмә уен кораллары (симфоник, камера, эстрада-симфоник оркестрларында), флейталар, гобойлар, фаготлар концертмейстерлары һәм концертмейстер урынбасарлары; беренче, икенче һәм өченче кларнетлар валторналар, саксофоннар, трубалар, тромбоннар, тубалар, кларнетлар, баритоннар, тенорлар, бәрмә уен кораллары, контрабаслар (тынлы оркестрларда), концертмейстерлары һәм концертмейстер урынбасарлары, оркестрның рус халык уен коралларында (балалайка, думбра, баян, гөслә, жалейка, Владимир быргысы) виртуозларча уйнаучы солисты | 26 000 |
| Лектор-сәнгать белгече (музыка белгече) | 26 000 |
| Баш режиссер (баш дирижер, баш балетмейстер, сәнгать җитәкчесе) ярдәмчесе, труппа мөдире | 26 000 |
| Сәнгатьле укучы – нәфис сүз остасы | 26 000 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | |



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| Вазифа атамасы | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда |
|---|---|
| Җыр һәм бию ансамбльләре оркестры артисты, эстрада оркестры (ансамбль) артисты – әйдәүче концертмейстер, уен кораллары төркеме җитәкчесе | 26 000 |
| Симфоник, камера, эстрада-симфоник, тынлы оркестр, халык уен кораллары оркестры артисты – беренче скрипкалар һәм виолончельләр концертмейстеры һәм концертмейстеры урынбасары, икенче скрипка, альт, контрабас-тромбон, туба, агач һәм бакыр тынлы уен коралларының беренче тавышлары һәм аларны көйләүчеләр, беренче арфа, литавра, рояль, гитара, аккордеон, вак бәрмә кораллар, бәрмә уен кораллары җайланмасы | 26 000 |
| «Башкару сәнгате учреждениеләренең җитәкче составы вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | |
| Тавыш режиссеры | 26 300 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән тыш, режиссер (дирижер, балетмейстер, хормейстер) | 26 300 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән тыш, куючы балетмейстер | 26 300 |
| Иҗат коллективы, цирк конвейеры программасы директоры | 26 300 |
| Музыка бүлеге мөдире, өченче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән тыш | 26 300 |
| Сәнгать-кую бүлеге мөдире, өченче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән тыш | 26 300 |
| Опера һәм балет театрлары режиссеры (дирижеры, балетмейстеры, хормейстеры) | 26 300 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән тыш, куючы режиссер | 26 300 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән әдәби-драматургия бүлеге җитәкчесе | 26 300 |

| Вазифа атамасы | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда |
|---|---|
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | |
| Опера һәм балет театрларында куючы балетмейстер | 26 300 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән кала, баш балетмейстер | 26 300 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән кала, баш дирижер | 26 300 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән кала, баш режиссер | 26 300 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән кала, баш хормейстер | 26 300 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән кала, баш рәссам | 26 300 |
| Опера һәм балет театрларында, музыкаль комедия театрларында, музыкаль-драма театрларында, яшь тамашачы театрларында, курчак театрларында, мөстәкыйль музыка һәм бию коллективларында, циркларда музыка бүлеге мөдире | 26 300 |
| Опера һәм балет театрларында, музыкаль комедия театрларында, музыка-драма, драма театрларында, яшь тамашачы театрларында, курчак театрларында, мөстәкыйль музыка һәм бию коллективларында, концерт залларында, циркларда әдәби-сәхнәләштерү бүлеге мөдире | 26 300 |
| Опера һәм балет театрларында куючы режиссер | 26 300 |
| Опера һәм балет театрларында әдәбият-драматургия бүлеге җитәкчесе | 26 300 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | |
| Опера һәм балет театрларында, музыкаль комедия театрларында, музыкаль-драма театрларында, циркларда, мөстәкыйль музыка һәм бию коллективларында баш балетмейстер | 26 300 |
| Опера һәм балет театрларында, музыкаль комедия театрларында, музыка-драма театрларында, яшь тамашачы театрларында, курчак театрларында, мөстәкыйль музыка | 26 300 |

| Вазифа атамасы | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда |
|---|---|
| һәм бию коллективларында, филармония һәм концерт оешмалары составындагы симфоник, камера, тынлы оркестрларда һәм халык уен кораллары оркестрларында, циркларда баш дирижер | |
| Опера һәм балет театрларында, музыкаль комедия театрларында, музыка-драма театрларында, филармонияләрдә һәм концерт оешмаларында, мөстәкыйль музыка һәм бию коллективларында, циркларда баш хормейстер | 26 300 |
| Опера һәм балет театрларында, музыкаль комедия театрларында, музыкаль-драма, драма театрларында, яшь тамашачы театрларында, курчак театрларында, циркларда баш режиссер | 26 300 |
| Опера һәм балет театрларында, музыкаль комедия театрларында, музыкаль-драма театрларында, драма театрларында, яшь тамашачы театрларында, курчак театрларында, циркларда баш рәссам | 26 300 |

## III. Башкару сәнгате хезмәткәрләренең вазифаи окладларын формалаштыру тәртибе

Башкару сәнгате хезмәткәрләренең вазифаи оклады ($O_d$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times S,$$ монда:

$O_b$ – әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган башкару сәнгате хезмәткәрләренең төп окладя күләме;

S – башкару сәнгате хезмәткәре биләп торган ставкаларның факттагы саны.

## IV. Кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр

4.1. Стимуллаштыру характерындагы түләүләргә хезмәткәрне хезмәтнең сыйфат нәтиҗәсенә стимуллаштыруга, шулай ук башкарылган эш өчен кызыксындыруга юнәлдерелгән түләүләр керә.

4.2. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- осталык өчен түләүләр;
- актив концерт эшчәнлеге өчен түләүләр;
- эшнең интенсивлыгы өчен түләүләр;
- мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр;
- шәхси казанышлар өчен түләүләр;
- профиль буенча эш стажы өчен түләүләр;
- башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре;
- премия һәм башка кызыксындыру түләүләре.

4.3. Осталык өчен түләүләр ($B_m$) әйдәүче звенога караган башкару сәнгате хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_m = O_d \times \frac{D_m}{100\%},$$ монда:

$O_d$ – башкару сәнгате хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_m$ – осталык өчен өстәмә түләүләр күләме.

Осталык өчен өстәмә түләү күләмнәре 1 таблицада китерелгән.

1 таблица

**Осталык өчен өстәмә түләүләрнең күләмнәре**

| **Артист категориясе** | **Өстәмә түләүләр күләме, процентларда** |
|---|---|
| 2 нче пландагы артист | 2 |
| 1 нче пландагы артист | 4 |
| Әйдәүче сәхнә мастеры | 6 |

4.4. Казан шәһәренең «Казанның Ля Примавера камера оркестры» муниципаль автоном мәдәният учреждениесе коллективында актив концерт эшчәнлеге өчен түләүләр, Казан шәһәренең «Казанның Ля Примавера камера оркестры» муниципаль автоном мәдәният учреждениесе коллективында эшләгән өчен ай саен акчалата кызыксындыру түләүләре бирү турындагы нигезләмә нигезендә, Казан шәһәрендә, Татарстан Республикасында һәм аннан читтә иҗади эшчәнлекне популярлаштыру максатыннан концертлар үткәргән өчен (елына 45 концерттан да ким түгел) айлык өстәмәләр белән бергә, 1791,67 мең сумнан артмаган хезмәт өчен түләү фонды зурлыгы чикләрендә муниципаль учреждение

җитәкчесе тарафыннан билгеләнә.

Актив концерт эшчәнлеге өчен түләүләр Казан шәһәренең «Казанның Ля Примавера камера оркестры» муниципаль автоном мәдәният учреждениесенең барлык хезмәткәрләренә дә түләнергә мөмкин.

4.5. Хезмәт киеренкелеге өчен түләүләр ($B_{in}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{in} = O_d \times \frac{D_{in}}{100\%},\ \text{монда:}$$

$O_d$ – башкару сәнгате хезмәткәрләренең вазифаи окладлы;

$D_{in}$ – хезмәт киеренкелеге өчен өстәмә түләүләр күләме.

Хезмәт киеренкелеге өчен өстәмә түләүләр күләме 2 нче таблицада китерелгән.

2 нче таблица

**Хезмәт киеренкелеге өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Һөнәри квалификация төркеме исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмә түләүләр күләме, процентларда |
|---|---|---|
| Урта звенога караган башкару сәнгате хезмәткәрләре вазифалары | 1 | 10 |
| | 2 | 17 |
| Әйдәүче звенога караган башкару сәнгате хезмәткәрләре вазифалары | 1 | 10 |
| | 2 | 25 |
| | 3 | 35 |
| | 4 | 40 |
| | 5 | 43 |
| Башкару сәнгате учреждениеләренең җитәкче составы вазифалары | 1 | 30 |
| | 2 | 60 |
| | 3 | 70 |
| | 4 | 90 |

4.6. Мактаулы исемнәргә ия булган өчен түләүләр ($B_{pz}$) башкару сәнгате хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%}, \text{ монда:}$$

$O_d$ – башкару сәнгате хезмәткәрләренең вазифаи окладлы;
$D_{pz}$ – мактаулы исемнәр булган өчен өстәмә түләү күләме.

4.7. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 8 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 10 процент тәшкил итә.

«Халык артисты» һәм «Атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемнәр өчен өстәмәләр күләме 20 процент тәшкил итә.

Стимуллаштыру сыйфатындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикаларның мактаулы исемнәре исемлеге әлеге Нигезләмәнең кушымтасында китерелгән.

4.8. Мактаулы исемнәр алган өчен түләү күләмнәрен билгеләү мактаулы исем бирелгән көннән билгеләнә. Ике һәм аннан күбрәк мактаулы исемнәре булган башкару сәнгате хезмәткәрләренә мактаулы исемнәре булган өчен түләү башкару сәнгате хезмәткәре сайлаган бер мактаулы исем буенча билгеләнә.

4.9. Казан шәһәренең «Ля Примавера Казан камера оркестры» муниципаль автоном мәдәният учреждениесенең, Казан шәһәренең «С.Гобәйдулина исемендәге заманча музыка үзәге» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең, «Казан шәһәр филармониясе» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең иҗат коллективлары хезмәткәрләренә шәхси казанышлары өчен вазифаи окладның 65 процентына кадәр күләмдә түләүләр ($B_{pd}$) билгеләнә һәм алар түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pd} = O_d \times \frac{D_{pd}}{100\%}, \text{ монда:}$$

$O_d$ – башкару сәнгате хезмәткәрләренең вазифаи окладлы;
$D_{pd}$ – шәхси казанышлар өчен өстәмә түләү күләме.

Хезмәткәрләрнең шәхси казанышлары өчен түләү күләме 3 нче таблицада китерелгән.

3 нче таблица

**Хезмәткәрләрнең шәхси казанышлары өчен түләү күләме**

| Учреждение атамасы | Коллектив атамасы | Вазифа атамасы | Түләү күләме, процентларда |
|---|---|---|---|
| Казан шәһәренең «Ля Примавера Казан камера оркестры» муниципаль автоном мәдәният учреждениесе | La Primavera оркестры | Коллективның барлык хезмәткәрләре | 65 кә кадәр |
| Казан шәһәренең «София Гобәйдуллинаның заманча музыка үзәге» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе | С.Гобәйдуллинаның заманча музыка үзәге оркестры | Коллективның барлык хезмәткәрләре | 65 кә кадәр |
| «Казан шәһәр филармониясе» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе | «Казан» бию ансамбле (шул исәптән «Казан Нуры» халык уен кораллары орекстры) | Балет артистлары, оркестр артистлары | 65 кә кадәр |
| | «Идел егетләре» фольклор ансамбле | Балет артистлары, вокалчы артист, солист-инструменталист | 65 кә кадәр |
| | Казан шәһәр филармониясенең сәнгать-артист персоналы | Артистлар, солистлар, вокалчылар | 65 кә кадәр |

4.10. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр ($B_s$), профиль буенча эшнең дәвамлылыгыннан чыгып, һөнәри квалификация төркемнәре буенча билгеләнә

һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%}, \text{ монда:}$$

$O_d$ – башкару сәнгате хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_s$ – профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме.

Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме 4 нче таблицада китерелгән.

4 нче таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме**

| **Һөнәри квалификация төркеме исеме** | **Стаж төркеме** | **Өстәмә түләүләр күләме, процентларда** |
|---|---|---|
| Урта звенога караган башкару сәнгате хезмәткәрләре вазифалары | 3 елдан 10 елга кадәр | 12 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 14 |
| | 15 елдан 20 елга кадәр | 16 |
| | 20 елдан 25 елга кадәр | 18 |
| | 25 елдан артык | 22 |
| Әйдәүче звенога караган башкару сәнгате хезмәткәрләре вазифалары | 3 елдан 10 елга кадәр | 12 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 14 |
| | 15 елдан 20 елга кадәр | 16 |
| | 20 елдан 25 елга кадәр | 18 |
| | 25 елдан артык | 22 |

Документ создан в электронной форме. № 66796-ПСП от 07.06.2025. Исполнитель: Переводчики
Страница 39 из 132. Страница создана: 05.06.2025 15:36
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | |
|---|---|---|
| Башкару сәнгате учреждениеләренең җитәкче составы вазифалары | 3 елдан 10 елга кадәр | 12 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 14 |
| | 15 елдан 20 елга кадәр | 16 |
| | 20 елдан 25 елга кадәр | 18 |
| | 25 елдан артык | 22 |

4.11. Эшләү вакыты вазифа буенча эш стажына кертелә торган вазифалар (һөнәрләр) исемлеге Татарстан Республикасы мәдәният министры әмере белән раслана.

4.12. Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләме, әгәр стажныраслый торган документлар учреждениедә булса, профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкән көннән алып яисә стажны раслый торган кирәкле документ тапшырылган көннән алып билгеләнә (үзгәртелә).

4.13. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре башкару сәнгате хезмәткәрләренә билгеле бер вакыт аралыгында хезмәт нәтиҗәләре буенча билгеләнә. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе башлыгы әмере белән раслана торган башкару сәнгате хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының чик күрсәткечләренә ирешү башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре күләменә йогынты ясый торган төп критерий булып тора.

4.14. Башкару сәнгате хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары аларның җитәкчеләре тарафыннан раслана. Башкару сәнгате хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының конкрет билгеләре һәм түләүләр башкару шартлары, учреждение алдында торган бурычлардан чыгып, ел саен билгеләнә.

4.15. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре бирү күләме, тәртибе һәм шартлары учреждениенең локаль норматив хокукый актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнә.

4.16. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре ($B_k$) һөнәри квалификация төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_k = O_d \times \frac{D_k}{100\%}, \text{ монда:}$$

$O_d$ – башкару сәнгате хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_k$ – башкарыла торган эшләр сыйфаты өчен өстәмә түләүнең чик күләме.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмә түләүләрнең чик күләме 5 нче таблицада китерелгән.

5 таблица

**Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмә түләүләрнең чик күләмнәре**

| **Һөнәри квалификация төркеме исеме** | **Өстәмә түләүләр күләме, процентларда** |
|---|---|
| Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазифалары | 9 |
| Урта звенога караган башкару сәнгате хезмәткәрләре вазифалары | 15 |
| Әйдәүче звенога караган башкару сәнгате хезмәткәрләре вазифалары | 18 |
| Башкару сәнгате учреждениеләренең җитәкче составы вазифалары | 25 |

4.17. Премия һәм башка кызыксындыру түләүләре башкару сәнгате хезмәткәрләренә юбилей даталары, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алу белән бәйле рәвештә һәм учреждениенең локаль норматив актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнгән башка нигезләр буенча билгеле бер чор (ай, квартал, ел) өчен бер тапкыр билгеләнә.

4.18. Казан шәһәренең башкару сәнгате муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында»гы Указы белән билгеләнгән максатчан күрсәткечләрнең ирешелгән дәрәҗәсен саклап калу максатыннан төп эш урыны һәм төп вазифа буенча башкару сәнгате хезмәткәрләренә, акча булган очракта, бер тапкыр бүләкләү түләве бирелә. Күрсәтелгән максатларда түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме учреждениенең локаль норматив актлары белән

билгеләнә.

4.19. Премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләрен башкару күләме, тәртибе һәм шартлары учреждениенең локаль норматив хокукый актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнә.

## V. Учреждение җитәкчесенең, учреждение җитәкчесе урынбасарының, баш бухгалтерның хезмәт хакын билгеләү тәртибе

5.1. Учреждение (шул исәптән сәнгать учреждениесе) җитәкчесенең, учреждение җитәкчесе урынбасарының, баш бухгалтерның хезмәт хакы вазифаи окладлардан һәм стимуллаштыру һәм компенсация сыйфатындагы түләүләрдән тора.

5.2. Башкару сәнгате учреждениесе җитәкчесенең оклады, хезмәт өчен түләү төркеменә карап, мәдәният учреждениесен гамәлгә куючы тарафыннан елына бер тапкыр билгеләнә. Башкару сәнгате учреждениесе җитәкчесенең хезмәтенә түләү төркеме башкару сәнгате учреждениесе хезмәткәрләренең штат санына бәйле рәвештә билгеләнә.

5.3. Учреждение җитәкчеләре урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының окладлары әлеге учреждение җитәкчеләренең вазифаи окладларыннан 20-30 процентка түбәнрәк билгеләнә.

5.4. Җитәкчеләрнең хезмәте өчен түләү төркеме, җитәкчеләрнең хезмәт хакы күләмнәре 6 нчы таблицада күрсәтелгән.

6 нчы таблица

**Мәдәният учреждениеләре җитәкчеләренең окладлары**

| Учреждение төре | Айлык оклад күләме, мең сумнарда | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хезмәт өчен түләү төркеме | | | | | | | |
| | Хезмәткәрләрнең штат саны, ставкалар саны | | | | | | | |
| | 10,999 га кадәр | 11 дән 30,999 га кадәр | 31 дән 50,999 га кадәр | 51 дән 75,999 га кадәр | 76 дан 150,999 га кадәр | 151 дән 300,999 га кадәр | 301 дән 500,999 га кадәр | 501 дән артык |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| Театр | - | - | 47,0 | 49,0 | 52,0 | 62,0 | 62,0 | 67,0 |
| Концерт | - | 47,0 | 52,0 | 57,0 | 62,0 | 67,0 | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| оешмалары | | | | | | | | |
| Цирк | - | 42,0 | - | - | - | 52,0 | - | - |
| Башкалар | 30,0 | 45,0 | - | 46,0 | 47,0 | - | - | - |

5.5. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр башкару сәнгате учреждениесе җитәкчесенә, эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, башкару сәнгате учреждениесен гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Башкару сәнгате учреждениесе җитәкчесенә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр ай саен, бер еллык эш нәтиҗәләре буенча, әһәмиятле һәм аеруча әһәмиятле йөкләмәләрне үтәгән өчен бирелергә мөмкин.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен башкару сәнгате учреждениесе җитәкчесенә кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр күләме 5 нче таблицада бирелгән.

7 нче таблица

**Башкару сәнгате учреждениесе җитәкчеләре тарафыннан башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр күләме**

| Учреждение төре | Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен бер айга кызыксындыру характерындагы түләү күләме, мең сумнарда | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хезмәт өчен түләү төркеме | | | | | | | |
| | Хезмәткәрләрнең штат саны, ставкалар саны | | | | | | | |
| | 10,999 га кадәр | 11 дән 30,999 га кадәр | 31 дән 50,999 га кадәр | 51 дән 75,999 га кадәр | 76 дан 150,999 га кадәр | 151 дән 300,999 га кадәр | 301 дән 500,999 га кадәр | 501 дән артык |
| Театр | - | - | 6,0 | 6,5 | 6,5 | 7,0 | 7,0 | 7,5 |
| Концерт оешмалары | - | 6,0 | 6,5 | 7,0 | 7,0 | 7,5 | - | - |
| Цирк | - | 5,0 | - | - | - | 6,5 | - | - |
| Башкалар | 3,0 | 5,5 | - | 6,0 | 6,0 | - | - | - |

5.6. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен башкару сәнгате

учреждениесендәге җитәкче урынбасарына, баш бухгалтерга кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр, аларның эшчәнлеге нәтиҗәләрен исәпкә алып, локаль норматив актларда билгеләнгән нәтиҗәлелек критерийлары нигезендә билгеләнә. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен җитәкче урынбасарына, баш бухгалтерга кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр ай саен, бер еллык эш нәтиҗәләре буенча, әһәмиятле һәм аеруча әһәмиятле йөкләмәләрне үтәгән өчен бирелергә мөмкин. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен җитәкче урынбасарына, баш бухгалтерга кызыксындыру характерындагы түләүнең чик дәрәҗәсе башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен башкару сәнгате учреждениесе җитәкчесенә кызыксындыру сыйфатында түләнә торган түләүләрнең 80 проценты дәрәҗәсендә билгеләнә.

5.7. Башкару сәнгате учреждениеләре җитәкчеләренең, җитәкче урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең типлаштырылган критерийлары һәм аларның авырлык коэффициентлары башкару сәнгате учреждениеләрен гамәлгә куючы тарафыннан раслана.

5.8. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр ($B_k$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_k = B_c \times K_{vk}, \text{ монда:}$$

$B_c$ – башкару сәнгате учреждениесе җитәкчесе башкара торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру сыйфатындагы түләүләрнең 6 нчы таблицада билгеләнгән күләме.

$K_{vk}$ – сыйфат критерийларын үтәү коэффициенты.

5.9. Башкару сәнгате учреждениеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү һәм 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында»гы Россия Федерациясе Президенты Указы белән билгеләнгән максатчан күрсәткечләрне ирешелгән дәрәҗәдә саклап калу максатыннан, төп эш урыны буенча һәм төп вазифа буенча башкару сәнгате учреждениеләре җитәкчеләренә, учреждение җитәкчеләре урынбасарларына һәм баш бухгалтерларга, акча булган очракта, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү башкарыла. Күрсәтелгән максатларда түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме башкару сәнгате учреждениесен гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

5.10. Казан шәһәренең «Казанның Ля Примавера камера оркестры» муниципаль автоном мәдәният учреждениесе җитәкчесенә актив концерт эшчәнлеге өчен түләү, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе

башлыгы боерыгы нигезендә, Казан шәһәрендә, Татарстан Республикасында һәм аннан читтә иҗади эшчәнлекне популярлаштыру максатыннан концертлар үткәргән өчен (елына кимендә 45 концерттан да ким түгел) айлык өстәмәләр белән бергә, 1791,67 мең сумнан артмаган хезмәт өчен түләү фонды зурлыгы чикләрендә башкару сәнгате учреждениесен гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

5.11. Компенсация сыйфатындагы түләүләр муниципаль башкару сәнгате учреждениеләре җитәкчеләре, аларның урынбасарлары һәм баш бухгалтерлары өчен Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә раслана торган компенсация сыйфатындагы түләү төрләре исемлеге нигезендә билгеләнә.

## VI. Компенсация сыйфатындагы түләүләр

6.1. Компенсация сыйфатындагы түләүләргә түбәндәгеләр керә:

- зарарлы һәм (яисә) куркыныч һәм башка махсус хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче башкару сәнгате учреждениеләре хезмәткәрләренә түләүләр;

- нормаль шартлардан читләшкән шартларда (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазифаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен, төнлә эшләгән һәм нормаль шартлардан читләшкән башка шартларда эшләр башкарганда) эшләгән өчен түләүләр.

6.2. Компенсация сыйфатындагы түләүләр, аларны башкару күләмнәре һәм шартлары хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган хезмәт законнары һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә коллектив шартнамәләр, килешүләр, локаль норматив актлар белән һәм Казан шәһәре муниципаль башкару сәнгате учреждениеләренең хезмәткә түләүнең расланган фонды чикләрендә билгеләнә.

6.3. Зарарлы һәм (яки) куркыныч һәм башка махсус хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче башкару сәнгате хезмәткәрләренә компенсация сыйфатындагы түләү ($B_{kh}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = O_b \times \frac{D_{kh}}{100\%} \times \frac{H_{fk}}{H_n}, \text{ монда:}$$

$O_b$ – әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган башкару сәнгате хезмәткәрләренең төп оклады күләме;

$D_{kh}$ – компенсация сыйфатындагы түләүгә өстәмә түләү күләме;

$H_{fk}$ – законнар белән компенсация сыйфатындагы түләүләр карала торган, фактта эшләнгән вакыт, сәгатьләрдә;

$H_n$ – Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган башкару сәнгате хезмәткәрләренең хезмәт хакының нигез ставкасы (төп окладны) өчен сәгать нормасы.

Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартларында эшләүче башкару сәнгате хезмәткәрләренә эшләгән өчен компенсация сыйфатындагы түләүләр хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә 4 процент күләмендә билгеләнә.

6.4. Нормаль шартларга туры килмәгән шартларда эшләгән өчен (төрле квалификация буенча эшләр башкарганда, һөнәрләрне (вазифаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен, төнлә эшләгән өчен һәм нормаль шартларга туры килмәгән башка шартларда эшләр башкарганда) түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә.

## VII. Башкару сәнгате учреждениесенең хезмәткә түләү фондын оештыру һәм аннан файдалану тәртибе

7.1. Башкару сәнгате муниципаль учреждениеләренең хезмәткә түләү фондын формалаштыру норматив чыгымнар, кулланучылар һәм күрсәтелә торган хезмәтләр саны нигезендә билгеләнгән агымдагы финанс елына мәдәният учреждениесе акчалары күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм башкару сәнгате муниципаль учреждениесенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагыла.

7.2. Әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән вазифаи окладлар, кызыксындыру һәм компенсация сыйфатындагы түләүләр башкару сәнгате муниципаль учреждениеләренең барлык хезмәткәрләренә агымдагы финанс елына хезмәт өчен түләүгә башкару сәнгате учреждениесенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында каралган акчалар исәбеннән башкарыла.

7.3. Тиешле чор (ай, квартал, ел) өчен барлык финанс белән тәэмин итү чыганаклары, шул исәптән түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр хисабыннан муниципаль башкару сәнгате учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында барлыкка килгән хезмәт өчен түләү фондын экономияләү әлеге нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән аерым муниципаль башкару сәнгате учреждениеләренең локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру түләүләренә җибәрелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фонды экономияләнгәндә, кызыксындыру түләүләре, хезмәт өчен түләү фондында вазифаларның кайсы һөнәри-квалификация төркемендә экономия барлыкка килгән, шул төркем хезмәткәрләргә түләнә.

Казан шәһәренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре,

фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре һөнәрләре, гомумтармак эшче һөнәрләре, гомумтармак җитәкче, белгеч һәм хезмәткәр вазифалары, авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре, мәгариф хезмәткәрләре, медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре, муниципаль башкару сәнгате учреждениеләре хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә, шул чорда үтәлгән эш вакыты нормаларын (хезмәт бурычларын) исәпкә алып, тиешле чор өчен хезмәткә түләү фондын экономияләү хисабына башкарылган кызыксындыру түләвенең күләме агымдагы елның 1 гыйнварына 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында»гы федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен минималь түләү күләменнән өч тапкырдан да артмаска тиеш.

Хезмәт өчен түләү фондын экономияләү исәбенә Казан шәһәренең башкару сәнгате учреждениесе җитәкчесенә кызыксындыру түләүләре күләме башкарма сәнгать учреждениесен гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары хисабына, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, Казан шәһәренең башкару сәнгате учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында барлыкка килгән, хезмәткә түләү фондын экономияләүдән калган акчаны файдаланган өчен җаваплылык Казан шәһәре башкару сәнгате учреждениесе җитәкчесенә йөкләнә.

Казан шәһәренең башкару сәнгатенә карагaн муниципаль учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә кушымта

**Кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикаларның мактаулы исемнәре исемлеге**

| № т/б | Мактаулы исемнең, дәүләт бүләгенең аталышы |
|---|---|
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1 | Россия Федерациясенең халык рәссамы |
| 1.2 | Россия Федерациясенең атказанган рәссамы |
| 1.3 | Россия Федерациясенең атказанган артисты |
| 1.4 | Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 2.1 | Татарстан Республикасының халык язучысы |
| 2.2 | Татарстан Республикасының халык шагыйре |
| 2.3 | Татарстан Республикасының халык рәссамы |
| 2.4 | Татарстан Республикасының атказанган артисты |
| 2.5 | Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |
| 3.1 | СССРның халык рәссамы |

| №<br>т/б | **Мактаулы исемнең, дәүләт бүләгенең аталышы** |
|---|---|
| | 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре |
| 4.1 | Атказанган пропагандачы |
| 4.2 | Халык рәссамы |
| 4.3 | Атказанган рәссам |
| 4.4 | Халык язучысы |
| 4.5 | Атказанган язучы |
| 4.6 | Халык шагыйре |
| 4.7 | Халык җырчысы |
| 4.8 | Халык акыны |
| 4.9 | Атказанган журналист |
| 4.10 | Атказанган мәдәният эшлеклесе |
| 4.11 | Атказанган мәдәни-мәгърифәтчелек эше хезмәткәре |
| 4.12 | Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 4.13 | Атказанган китапханәче |
| 4.14 | Гамәли сәнгать остасы |
| 4.15 | Атказанган халык иҗаты остасы |
| 4.16 | Атказанган фән эшлеклесе |
| | 5. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автономияле республикаларның мактаулы исемнәре |
| 5.1 | Атказанган төзүче |
| 5.2 | Халык рәссамы |
| 5.3 | Атказанган рәссам |
| 5.4 | Халык язучысы |
| 5.5 | Атказанган язучы |
| 5.6 | Халык шагыйре |

| №<br>т/б | Мактаулы исемнең, дәүләт бүләгенең аталышы |
|---|---|
| 5.7 | Атказанган журналист |
| 5.8 | Атказанган китапханәче |
| 5.9 | Атказанган фән һәм мәдәният эшлеклесе |
| 5.10 | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 5.11 | Атказанган фән эшлеклесе |

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 12 маендагы
1421 номерлы карарына
3 номерлы кушымта

**Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләренең фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазифалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләренең фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазифалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү шартлары турындагы әлеге нигезләмә (алга таба – Нигезләмә, фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләре) хезмәткәрләрнең окладларын формалаштыру тәртибен, кызыксындыру һәм компенсация сыйфатындагы түләүләрнең шартларын һәм күләмнәрен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын билгели.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

- хезмәт өчен түләү системасы – төп окладларның, вазифаи окладларның күләмнәрен, шулай ук федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән компенсация һәм кызыксындыру сыйфатындагы түләүләрне дә кертеп, фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартларын һәм күләмнәрен билгели торган

нормалар җыелмасы;

- төп оклад – компенсация һәм кызыксындыру түләүләрен исәпкә алмыйча, тиешле һөнәри квалификация төркеменә керә торган эшче һөнәре яисә җитәкче, белгеч, техник башкаручы вазифасы буенча һөнәри эшчәнлек башкаручы фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәренең окладының;

- вазифаи оклад – компенсация һәм кызыксындыру түләүләрен исәпкә алмыйча, календарь ай өчен тиешле катлаулылыктагы хезмәт (вазифаи) бурычларын үтәгән өчен фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәренең хезмәтенә түләүнең билгеләнгән күләме;

- хезмәткәрнең хезмәт хакы (хезмәте өчен түләү) – фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәренең квалификациясенә, башкарыла торган эшнең катлаулылыгына, күләменә, сыйфатына һәм шартларына карап, хезмәт өчен түләү, шулай ук компенсация һәм кызыксындыру түләүләре;

- компенсация сыйфатындагы түләүләр – нормага туры килмәгән шартларда эшләгән өчен түләүләрне дә кертеп, компенсация сыйфатындагы өстәп һәм өстәмә түләүләр һәм компенсация сыйфатындагы башка түләүләр;

- кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр – кызыксындыру сыйфатындагы өстәп һәм өстәмә түләүләр, премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре.

1.3. Фәнни тикшеренү өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы (хезмәте өчен түләү) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

- окладлардан (вазифаи окладлар), хезмәт хакы ставкаларыннан;

- стимуллаштыру характерындагы түләүләрдән;

- компенсация характерындагы түләүләрдән.

1.4. Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәренең профиль буенча эш стажы артуга, квалификация категориясе бирелүгә, мактаулы исем бирелүгә бәйле рәвештә, фән докторы яки фән кандидаты гыйльми дәрәҗәсе бирелү белән бәйле, еллык яки башка ялда булу вакытында, вакытлыча хезмәткә яраксызлык чорында, шулай ук уртача хезмәт хакы саклана торган башка чорларга бәйле рәвештә хезмәтенә түләү күләме үзгәрүгә хокукы барлыкка килсә, аның хезмәтенә түләү күләме күрсәтелгән чорлар тәмамланганнан соң үзгәртелә.

## II. Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең төп окладларын билгеләү

| Вазифа атамасы | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда |
|---|---|
| Фәнни тикшеренүләр өлкәсе фәнни хезмәткәрләре һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифалары һөнәри квалификация төркеме | |

| Вазифа атамасы | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда |
|---|---|
| Фәнни хезмәткәрләр | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | |
| Кече фәнни хезмәткәр | 27 200 |
| Фәнни хезмәткәр | 27 200 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | |
| Өлкән фәнни хезмәткәр | 28 000 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | |
| Әйдәүче фәнни хезмәткәр | 28 500 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | |
| Баш фәнни хезмәткәр | 29 000 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | |
| Гыйльми секретарь | 29 000 |

«Музейның кече фәнни хезмәткәре» вазифасын биләгән хезмәткәрләрнең төп оклады 27 200 сум күләмендә билгеләнә.

«Музейның фәнни хезмәткәре» һәм «музейның өлкән фәнни хезмәткәре» вазифаларын били торган хезмәткәрләрнең төп окладына 28 000 сум күләмендә билгеләнә.

## III. Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең вазифаи окладларын формалаштыру тәртибе

Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең вазифаи окладлары ($O_d$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times S,$$ монда:

$O_b$ – әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең төп окладлары күләме;

S – фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәре биләп торган ставкаларның фактттагы саны.

## IV. Кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр

4.1. Кызыксындыру сыйфатындагы түләүләргә хезмәткәрне сыйфатлы хезмәт нәтиҗәсенә кызыксындыруга, шулай ук башкарган эш өчен бүләкләүгә юнәлдерелгән түләүләр керә.

4.2. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр;
- гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен түләүләр;
- профиль буенча эш стажы өчен түләүләр;
- башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре;
- премия һәм башка кызыксындыру түләүләре.

4.3. Мактаулы исемнәр ($B_{pz}$) булган өчен түләүләр фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$ монда:

$O_d$ – фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{pz}$ – мактаулы исемнәр булган өчен өстәмә түләү күләме.

4.4. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 8 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 10 процент тәшкил итә.

Стимуллаштыру сыйфатындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикаларның мактаулы исемнәре исемлеге әлеге Нигезләмәнең кушымтасында китерелгән.

4.5. Мактаулы исемнәр алган өчен түләү күләмнәрен билгеләү мактаулы исем бирелгән көннән билгеләнә. Ике һәм аннан күбрәк мактаулы исемгә ия фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә мактаулы исемнәре өчен түләү мактаулы исемнәрнең фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәре сайлап алган берсе буенча билгеләнә.

4.6. Гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен түләүләр ($B_{usz}$) фәнни

тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{usz} = O_d \times \frac{D_{usz}}{100\%},$$ монда:

$O_d$ – фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{usz}$ – гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен өстәмә түләүләр күләме.

4.7. Гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен түләү Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган Гыйльми дәрәҗәләрнең һәм исемнәрнең бердәм реестрына кертелгән гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр өчен бирелә.

Гыйльми дәрәҗә булган өчен түләүләр күләме гыйльми дәрәҗә бирү турындагы карар гамәлгә кергән көннән билгеләнә. Фәннәр докторы гыйльми дәрәҗәсен бирү турындагы карар Югары аттестация комиссиясе президиумы аны кабул иткән көннән гамәлгә керә. Фәннәр кандидаты гыйльми дәрәҗәсен бирү турындагы карар Югары аттестация комиссиясе президиумы тарафыннан фәннәр кандидаты дипломын бирү турында карар кабул ителгән көннән гамәлгә керә.

Гыйльми исемнәр булган өчен түләүләр күләме гыйльми исем бирелгән көннән билгеләнә.

Гыйльми дәрәҗәсе һәм гыйльми исеме булган фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен түләүләр күләме гыйльми дәрәҗә һәм гыйльми исем өчен түләүләр суммасы буларак исәпләнә.

Гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр өчен өстәмә түләүләр күләме 1 нче таблицада китерелгән.

1 таблица

**Гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен өстәмә түләүләр күләме**

| **Гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен өстәмә түләүләр билгеләү нигезе** | **Өстәмә түләүләр күләме, процентларда** | |
|---|---|---|
| | **муниципаль учреждениеләрдә** | **төбәк әһәмиятендәге учреждениеләрдә** |
| Фәнни хезмәткәрләр белгечлекләре номенклатурасы нигезендә фән тармагы буенча фәннәр докторы | 20 | 60 |

| Гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен өстәмә түләүләр билгеләү нигезе | Өстәмә түләүләр күләме, процентларда | |
|---|---|---|
| | **муниципаль учреждениеләрдә** | **төбәк әһәмиятендәге учреждениеләрдә** |
| гыйльми дәрәҗәсе | | |
| Фәнни хезмәткәрләр белгечлекләре номенклатурасы нигезендә фән тармагы буенча фәннәр кандидаты гыйльми дәрәҗәсе | 10 | 30 |
| Фәнни хезмәткәрләр белгечлекләре номенклатурасы нигезендә белгечлек буенча профессор гыйльми исеме | 40 | 80 |
| Фәнни хезмәткәрләр белгечлекләре номенклатурасы нигезендә белгечлек буенча доцент гыйльми исеме | 20 | 40 |

4.8. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр ($B_s$), профиль буенча эшнең дәвамлылыгыннан чыгып, һөнәри квалификация төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%}, \text{ монда:}$$

$O_d$ – фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_s$ – профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме.

Профиль буенча стаж өчен өстәмә түләүләр күләме 2 нче таблицада китерелгән.

2 нче таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Һөнәри квалификация төркеме исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Стаж буенча төркем | Өстәмә түләүләр күләме, процентларда |
|---|---|---|---|
| Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләре | 1-4 | 3 елдан 10 елга кадәр | 12 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | 10 елдан 15 елга кадәр | 14 |
| | | 15 елдан 20 елга кадәр | 16 |
| | | 20 елдан 25 елга кадәр | 18 |
| | | 25 елдан артык | 22 |

4.9. Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләме, әгәр стажны раслый торган документлар учреждениедә булса, профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкән көннән алып яисә стажны раслый торган кирәкле документ тапшырылган көннән алып билгеләнә (үзгәртелә).

4.10. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә билгеле бер вакыт аралыгында (ай, квартал, ел) хезмәт нәтиҗәләре буенча билгеләнә. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе башлыгы әмере белән раслана торган фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының чик күрсәткечләренә ирешү башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре күләменә йогынты ясый торган төп критерий булып тора.

4.11. Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары аларның җитәкчеләре тарафыннан раслана. Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының конкрет билгеләре һәм түләүләр башкару шартлары, учреждение алдында торган бурычлардан чыгып, ел саен билгеләнә.

4.12. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре бирү күләме, тәртибе һәм шартлары учреждениенең локаль норматив хокукый актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнә.

4.13. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре ($B_k$) һөнәри квалификация төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_k = O_d \times \frac{D_k}{100\%},$$ монда:

$O_d$ – фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_k$ – башкарыла торган эшләр сыйфаты өчен өстәмә түләүнең чик күләме.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмә түләүләрнең чик күләме 3 нче таблицада китерелгән.

3 нче таблица

**Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмә түләүләрнең чик күләмнәре**

| Һөнәри квалификация төркеме исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмә түләүләр күләме, процентларда |
|---|---|---|
| Фәнни тикшеренүләр өлкәсе фәнни хезмәткәрләре һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифалары һөнәри квалификация төркеме | 1 | 22 |
| | 2 | 22 |
| | 3 | 22 |
| | 4 | 40 |

4.14. Премия һәм башка кызыксындыру түләүләре фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә юбилей көннәре, хөрмәт билгеләре, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алуга бәйле рәвештә һәм учреждениенең локаль норматив актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнгән башка нигезләр буенча билгеле бер чор (ай, квартал, ел) өчен бер тапкыр билгеләнә.

4.15. Мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында»гы указы белән билгеләнгән максатчан күрсәткечләрнең ирешелгән дәрәҗәсен саклап калу максатыннан төп эш урыны һәм төп вазифа буенча фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләренә, акча булган очракта, бер тапкыр бүләкләү түләве бирелә. Күрсәтелгән максатларда түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме учреждениенең локаль норматив актлары белән билгеләнә.

4.16. Премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләрен башкару күләме, тәртибе һәм шартлары учреждениенең локаль норматив хокукый актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнә.

## V. Компенсация сыйфатындагы түләүләр

5.1. Компенсация сыйфатындагы түләүләргә түбәндәгеләр керә:

- эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр;
- зарарлы һәм (яисә) куркыныч һәм башка махсус хезмәт шартлары булган

эшләрдә эшләүче фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә түләүләр;

- нормаль шартлардан читләшкән шартларда (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазифаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен, төнлә эшләгән һәм нормаль шартлардан читләшкән башка шартларда эшләр башкарганда) эшләгән өчен түләүләр.

5.2. Компенсация сыйфатындагы түләүләр, аларны башкару күләмнәре һәм шартлары хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган хезмәт законнары һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә коллектив шартнамәләр, килешүләр, локаль норматив актлар белән һәм Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләренең хезмәткә түләүнең расланган фонды чикләрендә билгеләнә.

5.3. Эшчәнлек үзенчәлекләре өчен компенсация характерындагы түләүләр ($B_{sd}$) аерым муниципаль учреждениеләрдәге фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sd} = O_d \times \frac{D_{sd}}{100\%},$$ монда:

$O_d$ – фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{sd}$ – эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләү күләме.

Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләү күләмнәре 4 нче таблицада китерелгән.

5.4. Әлеге учреждениедә, бүлекчәдә һәм вазифада конкрет эш шартларын исәпкә алып, эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләр билгеләнә торган фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләре вазифалары исемлеге, сайлана торган профсоюз органы (яки хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен якларга вәкаләтле башка орган) белән килештереп, һәр учреждение тарафыннан раслана.

4 нче таблица

**Эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләрнең тәкъдим ителә торган күләме**

| № т/б | Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләү билгеләүнең нигезе | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмә түләүләр күләме, процентларда |
|---|---|---|---|
| 1 | Төбәк әһәмиятендәге мәдәният учреждениеләрендә эш | 1 | 20 |
| | | 2 | 25 |
| | | 3 | 30 |

| № т/б | Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләү билгеләүнең нигезе | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмә түләүләр күләме, процентларда |
|---|---|---|---|
| | | 4 | 40 |
| 2 | Төбәк әһәмиятендәге мәдәният учреждениеләрендә гамәли эштә ике дәүләт теле куллану | 1-4 | 10 |

5.5. Зарарлы һәм (яки) куркыныч һәм башка махсус хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә компенсация сыйфатындагы түләү ($B_{kh}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = O_b \times \frac{D_{kh}}{100\%} \times \frac{H_{fk}}{H_n},\ \text{монда:}$$

$O_b$ – әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең төп оклады;

$D_{kh}$ – компенсация сыйфатындагы түләүгә өстәмә түләү күләме;

$H_{fk}$ – законнар белән компенсация сыйфатындагы түләүләр карала торган, фактта эшләнгән вакыт, сәгатьләрдә;

$H_n$ – Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакының төп ставкасы (төп окладының) өчен сәгать нормасы.

Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартларында эшләүче фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә эшләгән өчен компенсация сыйфатындагы түләүләр хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә 4 процент күләмендә билгеләнә.

5.6. Нормаль шартларга туры килмәгән шартларда эшләгән өчен (төрле квалификация буенча эшләр башкарганда, һөнәрләрне (вазифаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен, төнлә эшләгән өчен һәм нормаль шартларга туры килмәгән башка шартларда эшләр башкарганда) түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә.

_______________

Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләренең фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазифалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә кушымта

**Кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикаларның мактаулы исемнәре исемлеге**

| № т/б | Мактаулы исемнең, дәүләт бүләгенең аталышы |
|---|---|
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1 | Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 1.2 | Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе |
| 1.3 | Россия Федерациясенең атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 1.4 | Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 2.1 | Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 2.2 | Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе |
| 2.3 | Татарстан Республикасының атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 2.4 | Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 3.1 | Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 3.2 | Атказанган халык мәгарифе хезмәткәре |
| 3.3 | Атказанган югары мәктәп эшлеклесе |



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| № т/б | Мактаулы исемнең, дәүләт бүләгенең аталышы |
|---|---|
| 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автономияле республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1 | Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 4.2 | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 4.3 | Атказанган фән һәм мәдәният эшлеклесе |
| 4.4 | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 4.5 | Атказанган фән эшлеклесе |

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 12 маендагы
1421 номерлы карарына
4 номерлы кушымта

**Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Казан шәһәренең муниципаль мәдәният учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре профессияләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы әлеге нигезләмә (алга таба – Нигезләмә, мәдәният эшчеләре) хезмәткәрләрнең окладларын формалаштыру тәртибен, кызыксындыру һәм компенсация сыйфатындагы түләүләрнең шартларын һәм күләмен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын билгели.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

- хезмәт өчен түләү системасы – төп окладларның, вазифаи окладларның күләмнәрен, шулай ук федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән компенсация һәм кызыксындыру сыйфатындагы түләүләрне дә кертеп, мәдәният эшчеләренең хезмәтенә түләү шартларын һәм күләмнәрен билгели торган нормалар җыелмасы;

- төп оклад – компенсация һәм кызыксындыру түләүләрен исәпкә алмыйча, тиешле һөнәри квалификация төркеменә керә торган эшче һөнәре яисә җитәкче, белгеч, техник башкаручы вазифасы буенча һөнәри эшчәнлек башкаручы мәдәният эшчесенең оклады;

- вазифаи оклад – компенсация һәм кызыксындыру түләүләрен исәпкә алмыйча, ставканы исәпкә алып, календарь ай өчен тиешле катлаулылыктагы хезмәт (вазифаи) бурычларын үтәгән өчен хезмәткәрнең хезмәтенә түләүнең билгеләнгән күләме;

- хезмәт хакы (хезмәткәрнең хезмәте өчен түләү) – мәдәният эшчесенең квалификациясенә, башкарыла торган эшнең катлаулылыгына, күләменә,

сыйфатына һәм шартларына карап, хезмәт өчен түләү, шулай ук компенсация һәм кызыксындыру түләүләре;

- компенсация сыйфатындагы түләүләр – нормага туры килмәгән шартларда эшләгән өчен түләүләрне дә кертеп, компенсация сыйфатындагы өстәп һәм өстәмә түләүләр һәм компенсация сыйфатындагы башка түләүләр;

- кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр – кызыксындыру сыйфатындагы өстәп һәм өстәмә түләүләр, премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре.

1.3. Мәдәният эшчесенең хезмәт хакы (хезмәте өчен түләү) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

- окладлардан (вазифаи окладлар), хезмәт хакы ставкаларыннан;
- стимуллаштыру характерындагы түләүләрдән;
- компенсация характерындагы түләүләрдән.

## II. Мәдәният эшчеләренең төп окладларын билгеләү

2.1. Мәдәният эшчеләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Бер айга төп оклад күләме, сумнарда** |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗәдәге гомумтармак эшче һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 19 242 |
| Икенче | 19 440 |
| «Икенче дәрәҗәдәге гомумтармак эшче һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 19 581 |
| Икенче | 19 755 |
| Өченче | 19 933 |
| Дүртенче | 20 464 |

**Эшче һөнәрләренең мәдәният эшчеләре һөнәрләре һөнәри квалификация дәрәҗәләре буенча бүленеше**

| № т/б | **Мәдәният эшчеләре һөнәрләре** |
|---|---|
| 1. «Беренче дәрәҗәдәге мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшче һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| 1.1 | Клавишалы уен кораллары детальләрен әзерләү автоматчысы |
| 1.2 | Телле музыка кораллары арматурачысы |
| 1.3 | Чиртмә уен кораллары аэрографисты |
| 1.4 | Бутафор |
| 1.5 | Музыка уен кораллары гарнировщигы |
| 1.6 | Күрек камераларын гофрлаучы |
| 1.7 | Гример-постижер |
| 1.8 | Уен автоматлары, аттракционнар һәм тир залында дежур торучы |
| 1.9 | Тавыш планкаларын ябыштыручы |
| 1.10 | Тавыш планкаларын әзерләүче |
| 1.11 | Тынлы уен кораллары өчен детальләр әзерләүче |
| 1.12 | Субтитрлар әзерләүче |
| 1.13 | Киномеханик |
| 1.14 | Клавиатурачы |
| 1.15 | Колорист |
| 1.16 | Музыкаль инструментлар детальләрен комплектлаучы |
| 1.17 | Контуровщик |
| 1.18 | Костюмер |
| 1.19 | Декорацияләр бизәүче маляр |
| 1.20 | Сәхнә машинисты |
| 1.21 | Негатив монтажлаучы |
| 1.22 | Позитив монтажлаучы |
| 1.23 | Сәхнә монтажлаучы |
| 1.24 | Перламутр эшкәртүче |

| № т/б | Мәдәният эшчеләре һөнәрләре |
|---|---|
| 1.25 | Магнит язмасы операторы |
| 1.26 | Клавишалы уен коралларының тавышын яхшырту стенды операторы |
| 1.27 | Яктыртучы |
| 1.28 | Диапозитив фильмнарны бизәүче |
| 1.29 | Субтитрлау бастыручы |
| 1.30 | Пиротехник |
| 1.31 | Мультипликация рәсемнәре өчен нигез әзерләүче |
| 1.32 | Музыка уен коралларын шомартучы |
| 1.33 | Постижер |
| 1.34 | Фильерлар шомартучы |
| 1.35 | Реквизитор |
| 1.36 | Субтитрларны ретушьлаучы |
| 1.37 | Тынлы уен коралларын җыючы |
| 1.38 | Бәрмә уен коралларын җыючы |
| 1.39 | Телле уен коралларын җыючы |
| 1.40 | Клавишалы уен коралларын җыючы-монтажлаучы |
| 1.41 | Смычоклы уен коралларын җыючы-монтажлаучы |
| 1.42 | Чиртмә уен коралларын җыючы-монтажлаучы |
| 1.43 | Махсус агач эшкәртү станоклары станокчысы |
| 1.44 | Махсус металл эшкәртү станоклары станокчысы |
| 1.45 | Декорацияләр әзерләү буенча столяр |
| 1.46 | Музыка уен кораллары детальләрен һәм төеннәрен әзерләү һәм ремонтлау столяры |
| 1.47 | Кыллар чорнаучы |
| 1.48 | Кыллар белән эшләүче |
| 1.49 | Мультипликацион пробалар төшерүче |

Документ создан в электронной форме. № 66796-ПСП от 07.06.2025. Исполнитель: Переводчики
Страница 66 из 132. Страница создана: 05.06.2025 15:36

| № т/б | Мәдәният эшчеләре һөнәрләре |
|---|---|
| 1.50 | Диапозитив фильмнарны урнаштыручы |
| 1.51 | Униформа эшчесе |
| 1.52 | Декорацияләр куючы |
| 1.53 | Лад пластиналарын урнаштыручы |
| 1.54 | Фильмнар тикшерүче |
| 1.55 | Фильмотека белән эшләүче |
| 1.56 | Фототека белән эшләүче |
| 2. «Икенче дәрәҗәдәге мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшче һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| 2.1. Беренче квалификация дәрәҗәсе | |
| 2.1.1. | Клавишлы уен кораллары рамнарын бронзалаучы |
| 2.1.2. | Видеотека белән эшләүче |
| 2.1.3. | Уен курчакларын әзерләүче |
| 2.1.4. | Клавишлы уен кораллары өчен чүкечләр әзерләүче |
| 2.1.5. | Музыка уен кораллары контролеры |
| 2.1.6. | Постижер производствосында буяучы |
| 2.1.7 | Җил җайланмаларына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.1.8 | Тавыш техникасына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.1.9. | Кинотелевидение җиһазларына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.1.10 | Төшерү аппаратурасына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.1.11 | Телевидение җиһазларына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.1.12 | Кинотехнология җиһазларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.1.13 | Пианино һәм рояльләрне көйләүче |
| 2.1.14 | Чиртмә уен коралларын көйләүче |
| 2.1.15. | Телле уен коралларын көйләүче |

| № т/б | Мәдәният эшчеләре һөнәрләре |
|---|---|
| 2.1.16. | Видеоязма операторы |
| 2.1.17. | Киноҗайланма белән идарә итү пульты операторы |
| 2.1.18. | Пианино һәм рояльләр көйләүче |
| 2.1.19. | Телле уен коралларын көйләүче |
| 2.1.20. | Клавишлы уен коралларын реставрацияләүче |
| 2.1.21. | Бәрмә уен коралларын реставрацияләүче |
| 2.1.22. | Фильм күчермәләрен реставрацияләүче |
| 2.1.23. | Чиртмә һәм смычкалы уен коралларын реставрацияләүче |
| 2.1.24. | Телле уен коралларын реставрацияләүче |
| 2.1.25. | Фонотека белән эшләүче |
| | 2.2. Икенче квалификация дәрәҗәсе |
| 2.2.1. | Уен курчакларын әзерләүче |
| 2.2.2. | Аерым заказлар буенча музыка коралларын әзерләүче |
| 2.2.3. | Интонировкалаучы |
| 2.2.4. | Постижер производствосында буяучы |
| 2.2.5. | Җил җайланмаларына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.2.6. | Тавыш техникасына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.2.7. | Кинотелевидение җиһазларына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.2.8. | Төшерү аппаратурасына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.2.9. | Телевидение җиһазларына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.2.10. | Кинотехнология җиһазларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.2.11. | Тынлы уен коралларын көйләүче |
| 2.2.12. | Смычоклы уен коралларын көйләүче-җайлаучы |
| 2.2.13. | Видеоязма операторы |
| 2.2.14. | Тынлы уен коралларын реставрацияләүче |

| № т/б | Мәдәният эшчеләре һөнәрләре |
|---|---|
| 2.2.15. | Фильм күчермәләрен реставрацияләүче |
| 2.3. Өченче квалификация дәрәҗәсе | |
| 2.3.1. | Кинотелевидение җиһазларына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.3.2. | Телевидение җиһазларына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.3.3. | Кинотехнология җиһазларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.3.4. | Видеоязма операторы |
| 2.4. Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | |
| Беренче-өченче квалификация дәрәҗәләренә караган, мөһим (аеруча мөһим) һәм җаваплы (аеруча җаваплы) эшләрне башкаручы эшче һөнәрләре | |
| 2.4.1. | Уен курчакларын әзерләүче |
| 2.4.2. | Аерым заказлар буенча музыка коралларын әзерләүче |
| 2.4.3. | Интонировкалаучы |
| 2.4.4. | Музыка уен кораллары контролеры |
| 2.4.5. | Постижер производствосында буяучы |
| 2.4.6. | Җил җайланмаларына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.4.7. | Тавыш техникасына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.4.8. | Кинотелевидение җиһазларына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.4.9. | Төшерү аппаратурасына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.4.10. | Телевидение җиһазларына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.4.11. | Кинотехнология җиһазларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.4.12. | Тынлы уен коралларын көйләүче |
| 2.4.13. | Пианино һәм рояльләрне көйләүче |
| 2.4.14. | Чиртмә уен коралларын көйләүче |
| 2.4.15. | Телле уен коралларын көйләүче |
| 2.4.16. | Смычоклы уен коралларын көйләүче-җайлаучы |

| № т/б | Мәдәният эшчеләре һөнәрләре |
|---|---|
| 2.4.17. | Видеоязма операторы |
| 2.4.18. | Пианино һәм рояльләр көйләүче |
| 2.4.19. | Тынлы уен коралларын реставрацияләүче |
| 2.4.20. | Клавишлы уен коралларын реставрацияләүче |
| 2.4.21. | Бәрмә уен коралларын реставрацияләүче |
| 2.4.22. | Фильм күчермәләрен реставрацияләүче |
| 2.4.23. | Чиртмә һәм смычкалы уен коралларын реставрацияләүче |
| 2.4.24. | Телле уен коралларын реставрацияләүче |

2.2. Берьюлы берничә вазифа башкаручы мәдәният эшчеләренә, шулай ук тулы булмаган эш вакыты шартларында хезмәт өчен түләү эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә яисә башкарылган эш күләменнән чыгып түләнә. Төп вазифа буенча, шулай ук өстәмә икенче вазифа буенча хезмәт хакы күләмнәре һәр вазифа буенча аерым билгеләнә.

## III. Мәдәният эшчеләренең вазифаи окладларын формалаштыру тәртибе

Мәдәният эшчеләренең вазифаи оклады ($O_d$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times \frac{H_f}{H_n}, \text{ монда:}$$

$O_b$ – әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә мәдәният эшчеләренең төп оклады күләме;

$H_f$ – хезмәткәр өчен билгеләнгән эш вакыты дәвамлылыгы чикләрендә мәдәният эшчеләренең факттагы эш сәгатьләре саны;

$H_n$ – мәдәният эшчеләренең хезмәт хакының төп ставкасы (төп оклад) өчен сәгатьләр нормасы (хезмәткәр өчен билгеләнгән эш вакытының дәвамлылыгы).

## IV. Кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр

4.1. Кызыксындыру сыйфатындагы түләүләргә хезмәткәрне сыйфатлы


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

хезмәт нәтиҗәсенә кызыксындыруга, шулай ук башкарган эш өчен бүләкләүгә юнәлдерелгән түләүләр керә.

4.2. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр;

- премия һәм башка кызыксындыру түләүләре.

4.3. Мактаулы исемнәргә ия булган өчен түләүләр ($B_{pz}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%}, \text{ монда:}$$

$O_d$ – мәдәният эшчеләренең вазифаи окладлары;

$D_{pz}$ – мактаулы исемнәр булган өчен өстәмә түләү күләме.

4.4. Мактаулы исемнәргә ия булган өчен өстәмә түләү күләме 3 процент тәшкил итә.

4.5. Стимуллаштыру сыйфатындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикаларның мактаулы исемнәре исемлеге әлеге Нигезләмәнең кушымтасында китерелгән.

4.6. Мактаулы исемнәр алган өчен түләү күләмнәрен билгеләү мактаулы исем бирелгән көннән билгеләнә. Ике һәм аннан күбрәк мактаулы исемнәре булган мәдәният эшчеләренә мактаулы исемнәре булган өчен түләү хезмәткәр сайлаган бер мактаулы исем буенча билгеләнә.

4.7. Премия һәм башка кызыксындыру түләүләре мәдәният эшчеләренә юбилей көннәре, хөрмәт билгеләре, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алуга бәйле рәвештә һәм учреждениенең локаль норматив актлары һәм коллектив шартнамәләр белән билгеләнгән башка нигезләр буенча билгеле бер чор (ай, квартал, ел) өчен, шулай ук бер тапкыр билгеләнә.

4.8. Премия һәм башка кызыксындыру түләүләрен башкару күләме, тәртибе һәм шартлары Казан шәһәре мәдәният учреждениеләренең локаль норматив актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнә.

4.9. Мәдәният эшчеләренә премия түләүләренә каралган хезмәт өчен түләү фондының тәкъдим ителә торган күләме хезмәт хакын түләүгә каралган фондның (хезмәт хакы, вазифаи оклад ставкалары) һәм төп вазифа һәм төп эш урыны буенча хезмәткәрләргә кызыксындыру сыйфатындагы түләүләрнең кимендә 2 процентын тәшкил итә.

4.10. Мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында»гы Указы белән билгеләнгән максатчан күрсәткечләрнең ирешелгән дәрәҗәсен саклап калу максатыннан төп эш урыны һәм төп вазифа буенча мәдәният өлкәсе эшчеләренә, акча булган очракта, бер тапкыр бүләкләү түләве бирелә. Күрсәтелгән максатларда түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме учреждениенең локаль норматив актлары белән билгеләнә.

4.11. Премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләрен башкару күләме, тәртибе һәм шартлары учреждениенең локаль норматив хокукый актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнә.

## V. Компенсация сыйфатындагы түләүләр

5.1. Компенсация сыйфатындагы түләүләргә түбәндәгеләр керә:

- зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартларында эшләүче мәдәният эшчеләренә түләүләр;

- нормаль шартларга туры килмәгән шартларда (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазифаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен, төнлә эшләгән һәм нормаль шартлардан читләшкән башка шартларда эшләр башкарганда) эшләгән өчен түләүләр.

5.2. Компенсация сыйфатындагы түләүләр, аларны башкару күләмнәре һәм шартлары хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган хезмәт законнары һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә коллектив шартнамәләр, килешүләр, локаль норматив актлар белән һәм Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләренең хезмәткә түләүнең расланган фонды чикләрендә билгеләнә.

5.3. Зарарлы һәм (яки) куркыныч һәм башка махсус хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче мәдәният эшчеләренә компенсация сыйфатындагы түләүләр ($B_{kh}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = O_b \times \frac{D_{kh}}{100\%} \times \frac{H_{fk}}{H_n},$$ монда:

$O_b$ – мәдәният эшчеләренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган төп оклады;

$D_{kh}$ – компенсация сыйфатындагы түләүгә өстәмә түләү күләме;

$H_{fk}$ – законнар белән компенсация сыйфатындагы түләүләр карала торган,

фактта эшләнгән вакыт, сәгатьләрдә;

$H_n$ – мәдәният эшчеләренең хезмәт хакы буенча Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган төп ставкасы (төп окладыы) өчен сәгатьләр нормасы.

Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартларында эшләүче мәдәният эшчеләренә эшләгән өчен компенсация сыйфатындагы түләүләр хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә 4 процент күләмендә билгеләнә.

5.4. Нормаль шартларга туры килмәгән шартларда эшләгән өчен (төрле квалификация буенча эшләр башкарганда, һөнәрләрне (вазифаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен, төнлә эшләгән өчен һәм нормаль шартларга туры килмәгән башка шартларда эшләр башкарганда) түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә.

Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә кушымта

**Кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикаларның мактаулы исемнәре исемлеге**

| № т/б | Мактаулы исемнең, дәүләт бүләгенең аталышы |
|---|---|
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1 | Россия Федерациясенең халык артисты |
| 1.2 | Россия Федерациясенең халык рәссамы |
| 1.3 | Россия Федерациясенең атказанган артисты |
| 1.4 | Россия Федерациясенең атказанган уйлап табучысы |
| 1.5 | Россия Федерациясенең атказанган конструкторы |
| 1.6 | Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 1.7 | Россия Федерациясенең атказанган рационализаторы |
| 1.8 | Россия Федерациясенең атказанган рәссамы |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 2.1 | Татарстан Республикасының халык артисты |
| 2.2 | Татарстан Республикасының халык язучысы |
| 2.3 | Татарстан Республикасының халык шагыйре |
| 2.4 | Татарстан Республикасының халык рәссамы |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| № т/б | Мактаулы исемнең, дәүләт бүләгенең аталышы |
|---|---|
| 2.5 | Татарстан Республикасының атказанган артисты |
| 2.6 | Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 2.7 | Татарстан Республикасының атказанган уйлап табучысы |
| 2.8 | Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 2.9 | Татарстан Республикасының атказанган рационализаторы |
| 2.10 | Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |
| 3.1 | СССРның халык артисты |
| 3.2 | СССРның халык рәссамы |
| 3.3 | СССРның атказанган уйлап табучысы |
| 3.4 | СССРның атказанган төзүчесе |
| 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1 | Атказанган полиграфист |
| 4.2 | Атказанган пропагандачы |
| 4.3 | Халык артисты |
| 4.4 | Атказанган артист |
| 4.5 | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 4.6 | Халык рәссамы |
| 4.7 | Атказанган рәссам |
| 4.8 | Халык язучысы |
| 4.9 | Атказанган язучы |
| 4.10 | Халык шагыйре |
| 4.11 | Халык җырчысы |
| 4.12 | Халык акыны |
| 4.13 | Атказанган журналист |

| № т/б | Мактаулы исемнең, дәүләт бүләгенең аталышы |
|---|---|
| 4.14 | Атказанган мәдәният эшлеклесе |
| 4.15 | Атказанган мәдәни-мәгърифәтчелек эше хезмәткәре |
| 4.16 | Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 4.17 | Атказанган китапханәче |
| 4.18 | Атказанган келәм тукучы |
| 4.19 | Гамәли сәнгать остасы |
| 4.20 | Атказанган халык иҗаты остасы |
| 4.21 | Атказанган фән эшлеклесе |
| 4.22 | Атказанган инженер |
| 4.23 | Атказанган уйлап табучы |
| 4.24 | Атказанган рационализатор |
| 4.25 | Атказанган оста |
| 5. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автономияле республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 5.1 | Атказанган төзүче |
| 5.2 | Халык артисты |
| 5.3 | Атказанган артист |
| 5.4 | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 5.5 | Халык рәссамы |
| 5.6 | Атказанган рәссам |
| 5.7 | Халык язучысы |
| 5.8 | Атказанган язучы |
| 5.9 | Халык шагыйре |
| 5.10 | Атказанган журналист |
| 5.11 | Атказанган мәдәният хезмәткәре |

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 12 маендагы
1421 номерлы карарына
5 номерлы кушымта

**Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләренең гомумтармак эшче һөнәрләре һәм гомумтармак җитәкче, белгеч һәм хезмәткәр вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләренең гомумтармак эшче һөнәрләре һәм гомумтармак җитәкче, белгеч һәм хезмәткәр вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы әлеге нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) хезмәткәрләрнең окладларын формалаштыру тәртибен, компенсация һәм стимуллаштыру сыйфатындагы түләүләр шартларын һәм күләмен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын билгели.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

- хезмәт өчен түләү системасы – төп окладларның, вазифаи окладларның күләмнәрен, шулай ук федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән компенсация һәм кызыксындыру сыйфатындагы түләүләрне дә кертеп, учреждение хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартларын һәм күләмнәрен билгели торган нормалар җыелмасы;

- төп оклад – компенсация һәм кызыксындыру түләүләрен исәпкә алмыйча, тиешле һөнәри квалификация төркеменә керә торган эшче һөнәре яисә җитәкче, белгеч, техник башкаручы вазифасы буенча һөнәри эшчәнлек башкаручы учреждение хезмәткәренең оклады;

- вазифаи оклад – компенсация һәм кызыксындыру түләүләрен исәпкә алмыйча, ставканы исәпкә алып, календарь ай өчен тиешле катлаулылыктагы хезмәт (вазифаи) бурычларын үтәгән өчен хезмәткәрнең хезмәтенә түләүнең билгеләнгән күләме;

- хезмәт хакы (хезмәткәрнең хезмәте өчен түләү) – хезмәткәрнең квалификациясенә, башкарыла торган эшнең катлаулылыгына, күләменә,

сыйфатына һәм шартларына карап, хезмәт өчен түләү, шулай ук компенсация һәм кызыксындыру түләүләре;

- компенсация сыйфатындагы түләүләр – нормага туры килмәгән шартларда эшләгән өчен түләүләрне дә кертеп, компенсация сыйфатындагы өстәп һәм өстәмә түләүләр һәм компенсация сыйфатындагы башка түләүләр;
- кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр – кызыксындыру сыйфатындагы өстәп һәм өстәмә түләүләр, премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре.

1.3. Гомумтармак эшче һөнәрләре һәм гомумтармак җитәкче, белгеч һәм хезмәткәр вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт хакы түбәндәгеләрне исәпкә алып билгеләнә:

- окладлардан (вазифаи окладлар), хезмәт хакы ставкаларыннан;
- стимуллаштыру характерындагы түләүләрдән;
- компенсация характерындагы түләүләрдән.

## II. Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләре җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең гомумтармак һөнәрләре хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладларын билгеләү

2.1. Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләренең гомумтармак эшче һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗәдәге гомумтармак эшче һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 19 242 |
| Икенче | 19 440 |
| «Икенче дәрәҗәдәге гомумтармак эшче һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 19 581 |
| Икенче | 19 755 |
| Өченче | 19 933 |
| Дүртенче | 20 464 |

2.2. Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләре җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗәдәге гомумтармак хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 19 242 |
| Икенче | 19 440 |
| «Икенче дәрәҗәдәге гомумтармак хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 19 581 |
| Икенче | 19 755 |
| Өченче | 19 933 |
| Дүртенче | 20 160 |
| Бишенче | 20 346 |
| «Өченче дәрәҗәдәге гомумтармак хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 20 536 |
| Икенче | 20 729 |
| Өченче | 20 926 |
| Дүртенче | 21 127 |
| Бишенче | 21 353 |
| «Дүртенче дәрәҗәдәге гомумтармак хезмәткәрләр вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 22 265 |
| Икенче | 22 465 |
| Өченче | 22 665 |

2.3. Гомумтармак эшче һәм хезмәткәр һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәренең җитәкчеләр, гомумтармак белгечләре һәм хезмәткәрләре вазифаларының квалификация дәрәҗәләренә туры килүе Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының норматив хокукый актлары нигезендә кабул ителә.

2.4. Икенче эштә эшләүче, шулай ук тулы булмаган эш вакыты шартларында эшләүче хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә яисә эшләнгән эш күләменнән чыгып башкарыла. Төп вазифа буенча, шулай ук өстәмә икенче вазифа буенча хезмәт хакы күләмнәре һәр вазифа буенча аерым билгеләнә.

## III. Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләренең гомумтармак эшче һөнәрләре һәм гомумтармак җитәкче, белгеч һәм хезмәткәр вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең вазифаи окладларын формалаштыру тәртибе

Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләренең гомумтармак эшче һөнәрләре һәм гомумтармак җитәкче, белгеч һәм хезмәткәр вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең вазифаи оклады ($O_d$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times \frac{H_f}{H_n}, \text{ монда:}$$

$O_b$ – Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләренең гомумтармак эшче һөнәрләре һәм гомумтармак җитәкче, белгеч һәм хезмәткәр вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган төп оклады күләме;

$H_f$ – Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәткәр өчен билгеләнгән эш вакыты дәвамлылыгы чикләрендә факттагы эш сәгатьләре саны;

$H_n$ – Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакының төп ставкасы (төп оклад) өчен сәгатьләр нормасы (хезмәткәр өчен билгеләнгән эш вакытының дәвамлылыгы).

## IV. Кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр

4.1. Кызыксындыру сыйфатындагы түләүләргә хезмәткәрне сыйфатлы хезмәт нәтиҗәсенә кызыксындыруга, шулай ук башкарган эш өчен бүләкләүгә юнәлдерелгән түләүләр керә.

4.2. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр;
- вазифа буенча эш стажы өчен түләүләр;
- премия һәм башка кызыксындыру түләүләре.

4.3. Мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр ($B_{pz}$) гомумтармак эшче һөнәрләре һәм гомумтармак җитәкче, белгеч һәм хезмәткәр вазифалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},\ \text{монда:}$$

$O_d$ – Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләренең гомумтармак эшче һөнәрләре һәм гомумтармак җитәкче, белгеч һәм хезмәткәр вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{pz}$ – мактаулы исемнәр булган өчен өстәмә түләү күләме.

4.4. Мактаулы исемнәргә ия булган өчен өстәмә түләү күләме 3 процент тәшкил итә.

4.5. Кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, бүләкләре, Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикаларның мактаулы исемнәре исемлеге әлеге Нигезләмәнең кушымтасында китерелгән.

4.6. Мактаулы исемнәр алган өчен түләү күләмнәрен билгеләү мактаулы исем бирелгән көннән билгеләнә. Ике һәм аннан күбрәк мактаулы исемнәре булган хезмәткәрләргә мактаулы исемнәре булган өчен түләү хезмәткәр сайлаган бер мактаулы исем буенча билгеләнә.

4.7. Вазифа (белгечлек) буенча эш стажы өчен түләүләр ($B_s$) гомумтармак эшче һөнәрләре һәм гомумтармак җитәкче, белгеч һәм хезмәткәр вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә, һөнәри-квалификация төркемнәре һәм квалификация дәрәҗәләре буенча, вазифада эшләү дәвамлылыгыннан чыгып, стаж төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

формула ярдәмендә исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$ монда:

$O_d$ – Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләре җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_s$ – вазифа буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме.

4.8. Вазифа буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме түбәндәгечә билгеләнә:

- вазифа буенча эш стажы 2 дән 5 елга кадәр булганда – 2,5 процент;
- вазифа буенча эш стажы 5 тән 10 елга кадәр булганда – 4 процент;
- вазифа буенча эш стажы 10 нан 15 елга кадәр булганда – 5 процент;
- вазифа буенча эш стажы 15 елдан артык булганда – 6 процент.

4.9. Эш стажы үзгәргәндә вазифа буенча эш стажы өчен түләү күләмнәрен билгеләү (үзгәртү) вазифа буенча эш стажы өчен түләү күләмен арттыруга хокук бирә торган стажга ирешү көненнән алып кирәкле документны тапшырган көннән башкарыла.

4.10. Вазифа буенча эш стажына, таблица нигезендә, вазифалар (һөнәрләр) буенча эш вакыты кертелә.

Таблица

**Әлеге вазифаларда эшләгән вакыт вазифа буенча эш стажына кертелә торган вазифалар (һөнәрләр) исемлеге**

| № т/б | Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре («баш», «өлкән» дигән вазифаи атамаларны да кертеп, барлык вазифа эчендәге категорияләр) хезмәткәрләре вазифалары атамалары | Кызыксындыру түләвен билгеләү өчен эшләү вакыты аралыгы белгечлек буенча эш стажына кертелә торган вазифалар (һөнәрләр) атамасы |
|---|---|---|
| 1 | Финанс бүлеге башлыгы, план-икътисад бүлеге башлыгы, баш бухгалтер урынбасары, бухгалтер, бухгалтер-ревизор, икътисадчы, бухгалтерлык исәбе һәм хуҗалык эшчәнлеген анализлау буенча икътисадчы, исәпләү | Финанс бүлеге начальнигы, план-икътисад бүлеге начальнигы, баш бухгалтер, бухгалтер-ревизор урынбасары, икътисадчы, бухгалтерлык исәбе һәм хуҗалык эшчәнлеген анализлау буенча икътисадчы, исәпләү (мәгълүмат-исәпләү) үзәгенең икътисадчысы, |

| № т/б | Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре («баш», «өлкән» дигән вазифаи атамаларны да кертеп, барлык вазифа эчендәге категорияләр) хезмәткәрләре вазифалары атамалары | Кызыксындыру түләвен билгеләү өчен эшләү вакыты аралыгы белгечлек буенча эш стажына кертелә торган вазифалар (һөнәрләр) атамасы |
|---|---|---|
| | (мәгълүмат-исәпләү) үзәге икътисадчысы, шартнамә һәм претензия эше буенча икътисадчы, планлаштыру буенча икътисадчы, сату буенча икътисадчы, финанс эше буенча икътисадчы, кассир, бәя билгеләүче | шартнамә һәм дәгъва эше буенча икътисадчы, матди-техник тәэмин итү буенча экономист, планлаштыру буенча икътисадчы, сату буенча икътисадчы, хезмәт буенча икътисадчы, финанс эше буенча икътисадчы, кассир, бәя билгеләүче |
| 2 | Матди-техник яктан тәэмин итү буенча икътисадчы | Матди-техник тәэмин итү икътисадчысы, матди-техник тәэмин итү бүлеге башлыгы, склад мөдире, бухгалтер, бухгалтер-ревизор, икътисадчы, бухгалтерлык исәбе һәм хуҗалык эшчәнлеген анализлау буенча икътисадчы, исәпләү (мәгълүмати-хисап) үзәгенең икътисадчысы, шартнамә һәм дәгъва эше буенча икътисадчы, планлаштыру буенча икътисадчы, сату буенча икътисадчы, финанс эше буенча икътисадчы, бәя билгеләүче, хисапчы |
| 3 | Хезмәтне оештыру һәм түләү бүлеге башлыгы, хезмәтне оештыру һәм җитештерү белән идарә итү лабораториясе (бюро) башлыгы, хезмәт буенча норматив-тикшеренү лабораториясе башлыгы, хезмәт социологиясе лабораториясе (бюросы) башлыгы, хезмәтне нормалаштыру буенча инженер, хезмәтне оештыру һәм нормалаштыру буенча инженер, хезмәтне оештыру буенча инженер, хезмәтне оештыру буенча техник, нарядчы, хронометражист | Хезмәтне оештыру һәм түләү бүлеге башлыгы, хезмәтне оештыру һәм җитештерү белән идарә итү лабораториясе (бюросы) башлыгы, хезмәт буенча норматив-тикшеренү лабораториясе башлыгы, хезмәт социологиясе лабораториясе (бюросы) башлыгы, социаль үсеш бүлеге башлыгы, хезмәт буенча икътисадчы, хезмәтне нормалаштыру буенча инженер, хезмәтне оештыру һәм нормалаштыру буенча инженер, хезмәтне оештыру буенча инженер, инструктор-дактилолог, хезмәт буенча техник, социолог, нарядчы, хронометражист |
- зарарлы һәм (яисә) куркыныч һәм башка махсус хезмәт шартлары булган

эшләрдә эшләүче авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә түләүләр;

- нормаль шартлардан читләшкән шартларда (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазифаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен, төнлә эшләгән һәм нормаль шартлардан читләшкән башка шартларда эшләр башкарганда) эшләгән өчен түләүләр.

5.2. Компенсация сыйфатындагы түләүләр, аларны башкару күләмнәре һәм шартлары хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган хезмәт законнары һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә коллектив шартнамәләр, килешүләр, локаль норматив актлар белән һәм Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләренең хезмәткә түләүнең расланган фонды чикләрендә билгеләнә.

5.3. Зарарлы һәм (яки) куркыныч һәм башка махсус хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә компенсация сыйфатындагы түләү ($B_{kh}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = O_b \times \frac{D_{kh}}{100\%} \times \frac{H_{fk}}{H_n},\ \text{монда:}$$

$O_b$ – әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренең төп оклады күләме;

$D_{kh}$ – компенсация сыйфатындагы түләүгә өстәмә түләү күләме;

$H_{fk}$ – законнар белән компенсация сыйфатындагы түләүләр карала торган, фактта эшләнгән вакыт, сәгатьләрдә;

$H_n$ – авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган төп ставка (төп оклад) өчен сәгатьләр нормасы.

Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартларында эшләүче авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә эшләгән өчен компенсация сыйфатындагы түләүләр хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә 4 процент күләмендә билгеләнә.

5.4. Нормаль шартларга туры килмәгән шартларда эшләгән өчен (төрле квалификация буенча эшләр башкарганда, һөнәрләрне (вазифаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен, төнлә эшләгән өчен һәм нормаль шартларга туры килмәгән башка шартларда эшләр башкарганда) түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә.

Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләренең авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазифалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә кушымта

**Кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикаларның мактаулы исемнәре исемлеге**

| № т/б | Мактаулы исемнең, дәүләт бүләгенең аталышы |
|---|---|
| | 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре |
| 1.1 | Россия Федерациясенең атказанган агрономы |
| 1.2 | Россия Федерациясенең атказанган ветеринария табибы |
| 1.3 | Россия Федерациясенең атказанган зоотехнигы |
| 1.4 | Россия Федерациясенең атказанган мелиораторы |
| 1.5 | Россия Федерациясенең атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы |
| 1.6 | Россия Федерациясенең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре |
| 1.7 | Россия Федерациясенең Атказанган рәссамы |
| | 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре |
| 2.1 | Татарстан Республикасының атказанган агрономы |
| 2.2 | Татарстан Республикасының атказанган ветеринария табибы |
| 2.3 | Татарстан Республикасының атказанган терлекчесе |
| 2.4 | Татарстан Республикасының атказанган зоотехнигы |
| 2.5 | Татарстан Республикасының атказанган мелиораторы |
| 2.6 | Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы |
| 2.7 | Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре |

| № т/б | **Мактаулы исемнең, дәүләт бүләгенең аталышы** |
|---|---|
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |
| 3.1 | СССРның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре |
| 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1 | Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре |
| 4.2 | Атказанган агроном |
| 4.3 | Атказанган авыл хуҗалыгы инженеры |
| 4.4 | Атказанган зоотехник |
| 4.5 | Атказанган терлекчелек хезмәткәре |
| 4.6 | Атказанган терлекче |
| 4.7 | Атказанган терлекчелек остасы |
| 4.8 | Терлекчелек остасы |
| 4.9 | Атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы |
| 4.10 | Атказанган механизатор |
| 4.11 | Атказанган мелиоратор |
| 4.12 | Атказанган ветеринария табибы |
| 5. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автономияле республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 5.1 | Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре |
| 5.2 | Атказанган агроном |
| 5.3 | Атказанган зоотехник |
| 5.4 | Атказанган терлекче |
| 5.5 | Атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы |
| 5.6 | Атказанган механизатор |
| 5.7 | Атказанган ветеринария табибы |

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 12 маендагы
1421 номерлы карарына
7 номерлы кушымта

**Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләре мәгариф хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләренең мәгариф хезмәткәрләре вазифалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү шартлары турында әлеге нигезләмә (алга таба – Нигезләмә, мәгариф хезмәткәрләре) мәгариф хезмәткәрләренең окладларын формалаштыру тәртибен, кызыксындыру һәм компенсация сыйфатындагы түләүләрнең шартларын һәм күләмен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын билгели.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

- хезмәт өчен түләү системасы – төп окладларның, вазифаи окладларның күләмнәрен, шулай ук федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән компенсация һәм кызыксындыру сыйфатындагы түләүләрне дә кертеп, мәгариф хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартларын һәм күләмнәрен билгели торган нормалар җыелмасы;

- төп оклад – компенсация һәм кызыксындыру түләүләрен исәпкә алмыйча, тиешле һөнәри квалификация төркеменә керә торган эшче һөнәре яисә җитәкче, белгеч, техник башкаручы вазифасы буенча һөнәри эшчәнлек алып баручы мәгариф хезмәткәренең оклады;

- вазифаи оклад – компенсация һәм кызыксындыру түләүләрен исәпкә алмыйча, ставканы исәпкә алып, календарь ай өчен тиешле катлаулылыктагы хезмәт (вазифаи) бурычларын үтәгән өчен мәгариф хезмәткәренең хезмәтенә түләүнең төгәл билгеләнгән күләме;

- хезмәт хакы (хезмәткәрнең хезмәте өчен түләү) – мәгариф хезмәткәренең квалификациясенә, башкарыла торган эшнең катлаулылыгына, күләменә, сыйфатына һәм шартларына карап, хезмәт өчен түләү, шулай ук компенсация

һәм кызыксындыру түләүләре;

- стимуллаштыру характерындагы түләүләр – стимуллаштыру сыйфатында өстәп һәм өстәмә түләүләр, премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре.

- компенсация характерындагы түләүләр – компенсация характерындагы, шул исәптән нормага туры килмәгән шартларда эшләгән өчен өстәп һәм өстәмә түләүләр һәм компенсация характерындагы башка түләүләр.

1.3. Мәгариф хезмәткәрләренең хезмәт хакы (хезмәте өчен түләү) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

- окладлардан (вазифаи окладлар), хезмәт хакы ставкаларыннан;
- стимуллаштыру характерындагы түләүләрдән;
- компенсация характерындагы түләүләрдән.

1.4. Хезмәткәрнең профиль буенча эш стажы артуга, квалификация категориясе бирелүгә, мактаулы исем бирелүгә бәйле рәвештә, еллык яки башка ялда булу вакытында, вакытлыча хезмәткә яраксызлык чорында, шулай ук уртача хезмәт хакы саклана торган башка чорларга бәйле рәвештә хезмәтенә түләү күләме үзгәрүгә хокукы барлыкка килсә, аның хезмәтенә түләү күләме күрсәтелгән чорлар тәмамланганнан соң үзгәртелә.

## II. Мәгариф хезмәткәрләренең төп окладларын билгеләү

| Вазифа атамасы | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда |
|---|---|
| Беренче дәрәҗәдәге ярдәмче укыту персоналының һөнәри-квалификация төркеме | |
| Уку часте секретаре | 19 515 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри-квалификация төркеме | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | |
| Концертмейстер | 20 800 |
| Өстәмә белем бирү педагогы | 20 800 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | |
| Тәрбияче | 20 900 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | |
| Укытучы (профессорлар-укытучылар составына кертелгән | 21 000 |

| Вазифа атамасы | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда |
|---|---|
| укытучы вазифаларыннан тыш) | |
| Өлкән методист | 21 000 |

## III. Мәгариф хезмәткәрләренең вазифаи окладларын формалаштыру тәртибе

Мәгариф хезмәткәрләренең вазифаи окладлары ($O_d$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times S,$$ монда:

$O_b$ – мәгариф хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган нигез окладлары күләме;

S – мәгариф хезмәткәре биләп тора торган ставкаларның факттагы саны.

## IV. Кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр

4.1. Стимуллаштыру характерындагы түләүләргә хезмәткәрне хезмәтнең сыйфат нәтиҗәсенә стимуллаштыруга, шулай ук башкарылган эш өчен кызыксындыруга юнәлдерелгән түләүләр керә.

4.2. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр;
- квалификация категориясе өчен түләүләр;
- профиль буенча эш стажы өчен түләүләр;
- башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре;
- премия һәм башка кызыксындыру түләүләре.

4.3. Мактаулы исемнәргә ия булган өчен түләүләр ($B_{pz}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$ монда:

$O_d$ – мәгариф хезмәткәрләренең вазифаи окладлары;

$D_{pz}$ – мактаулы исемнәр булган өчен өстәмә түләү күләме.

4.4. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 8 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 10 процент тәшкил итә.

Стимуллаштыру сыйфатындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикаларның мактаулы исемнәре исемлеге әлеге Нигезләмәнең кушымтасында китерелгән.

4.5. Мактаулы исемнәр алган өчен түләү күләмнәрен билгеләү мактаулы исем бирелгән көннән билгеләнә. Ике һәм аннан күбрәк мактаулы исемнәре булган мәгариф хезмәткәрләренә мактаулы исемнәре булган өчен түләү мәгариф хезмәткәре сайлаган бер мактаулы исем буенча билгеләнә.

4.6. Квалификация категориясе өчен түләүләр, һөнәри квалификация төркемнәреннән чыгып, аттестация йомгаклары буенча тариф-квалификация характеристикалары нигезендә квалификация категорияләре бирүне күз алдында тота торган белгечлекләр буенча эшләүче мәгариф хезмәткәрләренә бирелә. Квалификация категориясе өчен түләүләр ($B_{kk}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$ монда:

$O_d$ – мәгариф хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{kk}$ – квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме.

Квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләмнәре 1 нче таблицада китерелгән.

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясе төзелгән орган (учреждение) әмере датасы буенча башкарыла.

1 таблица

**Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме**

| **Квалификация - дәрәҗәсе** | **Квалификация категориясе** | **Өстәмә түләүләр күләме, процентларда** |
|---|---|---|


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| Педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри-квалификация төркеме | | |
|---|---|---|
| 2 | Беренче | 4,5 |
| | Югары | 6,0 |
| 3 | Беренче | 5,5 |
| | Югары | 7,0 |
| 4 | Беренче | 7,5 |
| | Югары | 9,0 |

4.7. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр ($B_s$), профиль буенча эшнең дәвамлылыгыннан чыгып, һөнәри квалификация төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$ монда:

$O_d$ – мәгариф хезмәткәрләренең вазифаи окладысы;

$D_s$ – профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме.

Профиль буенча стаж өчен өстәмә түләүләр күләме 2 нче таблицада китерелгән.

2 нче таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме**

| **Һөнәри квалификация төркеме исеме** | **Квалификация дәрәҗәсе** | **Стаж төркеме** | **Өстәмә түләүләр күләме, процентларда** |
|---|---|---|---|
| Педагогик хезмәткәр вазифалары | 2-4 | 2 елдан 6 елга кадәр | 3,0 |
| | | 6 елдан 10 елга кадәр | 4,5 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 5,5 |
| | | 15 елдан артык | 6,5 |

4.8. 3 нче таблица нигезендә, мәгариф һәм башка оешмалардагы педагогик, җитәкче һәм методик эш эш стажына исәпләнә.

3 нче таблица

**Аларда эшләү вакыты мәдәният учреждениеләренең мәгариф хезмәткәрләре стажына керә торган учреждениеләр, оешмалар һәм вазифалар исемлеге**

| Учреждение һәм оешма исеме | Вазифа атамасы |
|---|---|
| Белем бирү оешмалары (шул исәптән югары һөнәри белем бирү оешмалары, югары, урта хәрби белем бирү оешмалары, белгечләргә өстәмә һөнәри белем бирү (квалификация күтәрү) мәгариф оешмалары); балалар йортларына, балалар шифаханәләренә, клиникаларына, поликлиникаларына, хастаханәләренә һ.б. социаль хезмәт күрсәтә торган медицина оешмалары һәм оешмалар, шулай ук өлкәннәр оешмаларындагы балалар бүлекләре, палаталары | Эшчәнлекләре белем (тәрбия) бирү процессы, методик тәэмин итү белән бәйләнгән укытучылар, белем бирүчеләр, укытучы-дефектологлар, укытучы-логопедлар (логопедлар), укытучы-оештыручылар (тормыш эшчәнлеге куркынычсызлыгы нигезләрен, хәрби хезмәткә чакырылганчы әзерлек үтүне), физик тәрбия җитәкчеләре, өлкән мастерлар, җитештерүгә өйрәтү мастерлары (шул исәптән транспорт чараларын йөртергә, авыл хуҗалыгы машиналарында эшләргә өйрәтү, язу машинкаларында һәм башка оештыру техникасында эшләргә өйрәтү), өлкән методистлар, методистлар, өлкән инструктор-методистлар, инструктор-методистлар (шул исәптән физик культура һәм спорт, туризм буенча), концертмейстерлар, музыкаль җитәкчеләр, өлкән тәрбиячеләр, тәрбиячеләр, сыйныф җитәкчеләре, социаль педагоглар, педагог-психологлар, педагог-оештыручылар, өстәмә белем бирү педагоглары, өлкән тренер-укытучылар, тренер-укытучылар, өлкән вожатыйлар (пионервожатыйлар), физкультура инструкторлары, хезмәт инструкторлары, директорлар (башлыклар, мөдирләр), укыту, укыту-тәрбия, укыту-җитештерү, тәрбия, культура-тәрбия эшләре, җитештерүгә өйрәтү (эше), чит телләр, укыту-очышка әзерләү, гомуми белем алуга әзерләү, режим буенча директор (башлык, мөдир) урынбасарлары, |

| Учреждение һәм оешма исеме | Вазифа атамасы |
|---|---|
| | укыту бүлеге мөдире, гамәли эш, укыту-консультация пунктлары, логопедия пунктлары, интернат, бүлекчә, бүлек, лаборатория, кабинет, секция, филиал, курслар һәм башка структур бүлекчәләр мөдирләре (башлыклары); аккомпаниаторлар, культоештыручылар, экскурсоводлар; профессор-укытучылар составы |
| Барлык исемнәрдәге методик (укыту-методик) оешмалар (кем карамагында булуына карамастан) | Җитәкчеләр, аларның урынбасарлары, секторлар, кабинетлар, лабораторияләр, бүлек мөдирләре; эшчәнлекләре методик тәэмин итүгә бәйле фәнни хезмәткәрләр; өлкән методистлар, методистлар |
| Белем бирү белән идарә итү органнары һәм мәгариф оешмалары белән җитәкчелек итүче органнар (структур бүлекчәләр) | Җитәкче, инспектор вазифалары, методик вазифалар, инструкторлык, шулай ук башка белгеч вазифалары (икътисади, финанс, хуҗалык эшчәнлеге, төзелеш, тәэмин итү, эш башкару белән бәйле вазифаларда эшләүдән тыш) |

4.9. Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләме, әгәр стажны раслый торган документлар учреждениедә булса, профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкән көннән алып яисә стажны раслый торган кирәкле документ тапшырылган көннән алып билгеләнә (үзгәртелә).

4.10. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре мәгариф хезмәткәрләренә билгеле бер вакыт аралыгында (бер ай, квартал, бер ел) эш нәтиҗәләре буенча билгеләнә. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе башлыгы әмере белән раслана торган мәгариф хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының чик күрсәткечләренә ирешү башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре күләменә йогынты ясый торган төп критерий булып тора.

4.11. Мәгариф хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары аларның җитәкчеләре тарафыннан раслана. Мәгариф хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының конкрет билгеләре һәм түләүләр башкару шартлары, учреждение алдында торган бурычлардан чыгып, ел саен билгеләнә.

4.12. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре бирү күләме, тәртибе һәм шартлары учреждениенең локаль норматив хокукый актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнә.

4.13. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре ($B_k$) һөнәри квалификация төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_k = O_d \times \frac{D_k}{100\%}, \text{ монда:}$$

$O_d$ – мәгариф хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_k$ – башкарыла торган эшләр сыйфаты өчен өстәмә түләүнең чик күләме.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмә түләүләрнең чик күләме 4 нче таблицада китерелгән.

4 нче таблица

**Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмә түләүләрнең чик күләмнәре**

| Һөнәри квалификация төркеме исеме | Өстәмә түләүләр күләме, процентларда |
|---|---|
| Беренче дәрәҗәдәге ярдәмче укыту персоналының һөнәри-квалификация төркеме | 14 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри-квалификация төркеме | 38 |

4.14. Премия һәм башка кызыксындыру түләүләре мәгариф хезмәткәрләренә юбилей даталары, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алуга бәйле рәвештә һәм учреждениенең локаль норматив актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнгән башка нигезләр буенча билгеле бер чор (ай, квартал, ел) өчен бер тапкыр билгеләнә.

4.15. Мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында»гы Указы белән билгеләнгән максатчан күрсәткечләрнең ирешелгән дәрәҗәсен саклап калу максатыннан төп эш урыны һәм төп вазифа буенча мәгариф хезмәткәрләренә, акча булган очракта, бер тапкыр бүләкләү түләве

бирелә. Күрсәтелгән максатларда түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме учреждениенең локаль норматив актлары белән билгеләнә.

4.16. Премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләрен башкару күләме, тәртибе һәм шартлары учреждениенең локаль норматив хокукый актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнә.

## V. Компенсация сыйфатындагы түләүләр

5.1. Компенсация сыйфатындагы түләүләргә түбәндәгеләр керә:

- эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр;
- зарарлы һәм (яисә) куркыныч һәм башка махсус хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә түләүләр;
- нормаль шартлардан читләшкән шартларда (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазифаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен, төнлә эшләгән һәм нормаль шартлардан читләшкән башка шартларда эшләр башкарганда) эшләгән өчен түләүләр.

5.2. Компенсация сыйфатындагы түләүләр, аларны башкару күләмнәре һәм шартлары хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган хезмәт законнары һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә коллектив шартнамәләр, килешүләр, локаль норматив актлар белән һәм Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләренең хезмәткә түләүнең расланган фонды чикләрендә билгеләнә.

5.3. Эшчәнлек үзенчәлекләре өчен компенсация сыйфатындагы түләүләр ($B_{sd}$) мәгариф хезмәткәрләренә аерым учреждениеләрдә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sd} = O_d \times \frac{D_{sd}}{100\%}, \text{ монда:}$$

$O_d$ – мәгариф хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{sd}$ – эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләү күләме.

Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләү күләмнәре 5 нче таблицада китерелгән.

5.4. Әлеге учреждениедә, бүлекчәдә һәм вазифада конкрет эш шартларын исәпкә алып, эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләр билгеләнә торган мәгариф хезмәткәрләре вазифалары исемлеге, сайлана торган профсоюз органы (яки хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен якларга вәкаләтле башка орган) белән килештереп, һәр учреждение тарафыннан расланa.

5 таблица

**Эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләрнең тәкъдим ителә торган күләме**

| Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләү билгеләүнең нигезе | Өстәмә түләүләр күләме, процентларда |
| --- | --- |
| Цирк дисциплиналарын укыту | 50 |

5.5. Зарарлы һәм (яки) куркыныч һәм башка махсус хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче мәгариф хезмәткәрләренә компенсация сыйфатындагы түләү ($B_{kh}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = O_b \times \frac{D_{kh}}{100\%} \times \frac{H_{fk}}{H_n},$$ монда:

$O_b$ – мәгариф хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган нигез оклады күләме;

$D_{kh}$ – компенсация сыйфатындагы түләүгә өстәмә түләү күләме;

$H_{fk}$ – законнар белән компенсация сыйфатындагы түләүләр карала торган, фактта эшләнгән вакыт, сәгатьләрдә;

$H_n$ – мәгариф хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган төп ставкасы (төп оклады) өчен сәгатьләр нормасы.

Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартларында эшләүче мәгариф хезмәткәрләренә эшләгән өчен компенсация сыйфатындагы түләүләр хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә 4 процент күләмендә билгеләнә.

5.6. Нормаль шартларга туры килмәгән шартларда эшләгән өчен (төрле квалификация буенча эшләр башкарганда, һөнәрләрне (вазифаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен, төнлә эшләгән өчен һәм нормаль шартларга туры килмәгән башка шартларда эшләр башкарганда) түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә.


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Казан шәһәренең муниципаль мәдәният учреждениеләре мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә кушымта

**Кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикаларның мактаулы исемнәре исемлеге**

| № т/б | Мактаулы исемнең, дәүләт бүләгенең аталышы |
|---|---|
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1 | Россия Федерациясенең халык рәссамы |
| 1.2 | Россия Федерациясенең атказанган рәссамы |
| 1.3 | Россия Федерациясенең атказанган артисты |
| 1.4 | Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 1.5 | Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 2.1 | Татарстан Республикасының халык язучысы |
| 2.2 | Татарстан Республикасының халык шагыйре |
| 2.3 | Татарстан Республикасының халык рәссамы |
| 2.4 | Татарстан Республикасының атказанган артисты |
| 2.5 | Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 2.6 | Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |
| 3.1 | СССРның халык рәссамы |

| №<br>т/б | Мактаулы исемнең, дәүләт бүләгенең аталышы |
|---|---|
| 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1 | Атказанган пропагандачы |
| 4.2 | Халык рәссамы |
| 4.3 | Атказанган рәссам |
| 4.4 | Халык язучысы |
| 4.5 | Атказанган язучы |
| 4.6 | Халык шагыйре |
| 4.7 | Халык җырчысы |
| 4.8 | Халык акыны |
| 4.9 | Атказанган журналист |
| 4.10 | Атказанган мәдәният эшлеклесе |
| 4.11 | Атказанган мәдәни-мәгърифәтчелек эше хезмәткәре |
| 4.12 | Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 4.13 | Атказанган китапханәче |
| 4.14 | Гамәли сәнгать остасы |
| 4.15 | Атказанган халык иҗаты остасы |
| 4.16 | Атказанган фән эшлеклесе |
| 5. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автономияле республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 5.1 | Атказанган төзүче |
| 5.2 | Халык рәссамы |
| 5.3 | Атказанган рәссам |
| 5.4 | Халык язучысы |
| 5.5 | Атказанган язучы |
| 5.6 | Халык шагыйре |

| №<br>т/б | Мактаулы исемнең, дәүләт бүләгенең аталышы |
|---|---|
| 5.7 | Атказанган журналист |
| 5.8 | Атказанган китапханәче |
| 5.9 | Атказанган фән һәм мәдәният эшлеклесе |
| 5.10 | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 5.11 | Атказанган фән эшлеклесе |

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 12 маендагы
1421 номерлы карарына
8 номерлы кушымта

**Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләренең медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазифалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләренең медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазифалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү шартлары турында әлеге нигезләмә (алга таба – Нигезләмә, сәламәтлек саклау хезмәткәрләре) хезмәткәрләрнең окладларын формалаштыру тәртибен, кызыксындыру һәм компенсация сыйфатындагы түләүләрнең шартларын һәм күләмен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын билгели.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

- хезмәт өчен түләү системасы – төп окладларның, вазифаи окладларның күләмнәрен, шулай ук федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән компенсация һәм кызыксындыру сыйфатындагы түләүләрне дә кертеп, сәламәтлек саклау хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартларын һәм күләмнәрен билгели торган нормалар җыелмасы;

- төп оклад – компенсация һәм кызыксындыру түләүләрен исәпкә алмыйча, тиешле һөнәри квалификация төркеменә керә торган эшче һөнәре яисә җитәкче, белгеч, техник башкаручы вазифасы буенча һөнәри эшчәнлек алып баручы сәламәтлек саклау хезмәткәренең оклады;

- вазифаи оклад – компенсация һәм кызыксындыру түләүләрен исәпкә алмыйча, ставканы исәпкә алып, календарь ай өчен тиешле катлаулылыктагы хезмәт (вазифаи) бурычларын үтәгән өчен сәламәтлек саклау хезмәткәренең хезмәтенә түләүнең төгәл билгеләнгән күләме;

- хезмәт хакы (хезмәткәрнең хезмәте өчен түләү) – сәламәтлек саклау

хезмәткәренең квалификациясенә, башкарыла торган эшнең катлаулылыгына, күләменә, сыйфатына һәм шартларына карап, хезмәт өчен түләү, шулай ук компенсация һәм кызыксындыру түләүләре;

- компенсация сыйфатындагы түләүләр – нормага туры килмәгән шартларда эшләгән өчен түләүләрне дә кертеп, компенсация сыйфатындагы өстәп һәм өстәмә түләүләр һәм компенсация сыйфатындагы башка түләүләр;

- кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр – кызыксындыру сыйфатындагы өстәп һәм өстәмә түләүләр, премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре.

1.3. Сәламәтлек саклау хезмәткәрләренең хезмәт хакы (хезмәте өчен түләү) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

- окладлардан (вазифаи окладлар), хезмәт хакы ставкаларыннан;
- стимуллаштыру характерындагы түләүләрдән;
- компенсация характерындагы түләүләрдән.

1.4. Сәламәтлек саклау хезмәткәренең профиль буенча эш стажы артуга, квалификация категориясе бирелүгә, мактаулы исем бирелүгә бәйле рәвештә, еллык яки башка ялда булу вакытында, вакытлыча хезмәткә яраксызлык чорында, шулай ук уртача хезмәт хакы саклана торган башка чорларга бәйле рәвештә хезмәтенә түләү күләме үзгәрүгә хокукы барлыкка килсә, аның хезмәтенә түләү күләме күрсәтелгән чорлар тәмамланганнан соң үзгәртелә.

## II. Сәламәтлек саклау хезмәткәрләренә төп оклад билгеләү

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Вазифа атамасы** | **Бер айга төп оклад күләме, сумнарда** |
|---|---|---|
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Өченче | Шәфкать туташы (медицина хезмәткәре (ир-ат)) | 21 163 |
| | Массаж буенча шәфкать туташы (массаж буенча медицина хезмәткәре (ир-ат)) | |
| Бишенче | Өлкән шәфкать туташы (өлкән медицина хезмәткәре (ир-ат)) | 22 863 |
| «Табиблар һәм провизорлар» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән | 24 563 |

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа атамасы | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда |
|---|---|---|
| | табиб-белгечләрдән тыш) | |

## III. Сәламәтлек саклау хезмәткәрләренең вазифаи окладларын формалаштыру тәртибе

Сәламәтлек саклау хезмәткәрләренең вазифаи оклады ($O_d$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times S,$$ монда:

$O_b$ – сәламәтлек саклау хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган төп оклады күләме;

S – сәламәтлек саклау хезмәткәре биләп тора торган ставкаларның факттагы саны.

## IV. Кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр

4.1. Стимуллаштыру сыйфатындагы түләүләргә сәламәтлек саклау хезмәткәрен хезмәтнең сыйфат нәтиҗәсенә стимуллаштыруга, шулай ук башкарылган эш өчен кызыксындыруга юнәлдерелгән түләүләр керә.

4.2. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- квалификация категориясе өчен түләүләр;
- профиль буенча эш стажы өчен түләүләр;
- башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре;
- премия һәм башка кызыксындыру түләүләре.

4.3. Квалификация категориясе өчен түләүләр ($B_{kk}$), һөнәри квалификация төркемнәреннән чыгып, аттестация йомгаклары буенча тариф-квалификация характеристикалары нигезендә квалификация категорияләре бирүне күз алдында тота торган белгечлекләр буенча эшләүче сәламәтлек саклау хезмәткәрләренә бирелә. Квалификация категориясе өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$ монда:

$O_d$ – сәламәтлек саклау хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{kk}$ – квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме.

Квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләмнәре 1 нче таблицада китерелгән.

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясе төзелгән орган (учреждение) әмере датасы буенча башкарыла.

1 таблица

**Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме**

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Квалификация категориясе** | **Өстәмә түләүләр күләме, процентларда** |
|---|---|---|
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| 3 | Икенче | 4,5 |
| | Беренче | 5,0 |
| | Югары | 5,5 |
| 5 | Икенче | 4,5 |
| | Беренче | 5,0 |
| | Югары | 5,5 |
| «Табиблар һәм провизорлар» һөнәри квалификация төркеме | | |
| 1 | Икенче | 6,5 |
| | Беренче | 7,0 |
| | Югары | 7,5 |

4.4. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр ($B_s$), профиль буенча эшнең дәвамлылыгыннан чыгып, һөнәри квалификация төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$ монда:

$O_d$ – сәламәтлек саклау хезмәткәрләренең вазифаи окладына;


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

$D_s$ – профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме.

Профиль буенча стаж өчен өстәмә түләүләр күләме 2 нче таблицада китерелгән.

2 нче таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме**

| **Һөнәри квалификация төркеме исеме** | **Эш стажы** | **Түләү күләме, процентларда** |
|---|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы | 3 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 |
| | 15 елдан артык | 5,5 |
| Табиблар һәм провизорлар | 3 елдан 5 елга кадәр | 5,0 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 7,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 9,0 |
| | 15 елдан артык | 10,0 |

4.5. Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләме, әгәр стажны раслый торган документлар учреждениедә булса, профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкән көннән алып яисә стажны раслый торган кирәкле документ тапшырылган көннән алып билгеләнә (үзгәртелә).

4.6. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре сәламәтлек саклау хезмәткәрләренә билгеле бер вакыт аралыгында (бер ай, квартал, бер ел) эш нәтиҗәләре буенча билгеләнә. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе башлыгы әмере белән раслана торган мәдәният учреждениеләренең сәламәтлек саклау хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының чик күрсәткечләренә ирешү башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре күләменә йогынты ясый торган төп критерий булып тора.

4.7. Сәламәтлек саклау хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары аларның җитәкчеләре тарафыннан раслана. Сәламәтлек саклау хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының конкрет билгеләре һәм түләүләр башкару шартлары, учреждение алдында торган бурычлардан чыгып, ел саен билгеләнә.

4.8. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре бирү күләме, тәртибе һәм шартлары учреждениенең локаль норматив хокукый актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнә.

4.9. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре ($B_k$) һөнәри квалификация төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_k = O_d \times \frac{D_k}{100\%}, \text{ монда:}$$

$O_d$ – сәламәтлек саклау хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_k$ – башкарыла торган эшләр сыйфаты өчен өстәмә түләүнең чик күләме.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмә түләүләрнең чик күләме 3 нче таблицада китерелгән.

3 нче таблица

**Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмә түләүләрнең чик күләмнәре**

| **Һөнәри квалификация төркеме исеме** | **Өстәмә түләүләр күләме, процентларда** |
|---|---|
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» өченче дәрәҗәдәге һөнәри квалификация төркеме | 6 |
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» бишенче дәрәҗәдәге һөнәри квалификация төркеме | 9 |
| «Табиблар һәм провизорлар» икенче дәрәҗәдәге һөнәри квалификация төркеме | 9 |

4.10. Премия һәм башка кызыксындыру түләүләре сәламәтлек саклау хезмәткәрләренә юбилей даталары, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алуга бәйле рәвештә һәм учреждениенең локаль норматив актлары

һәм коллектив килешүләр белән билгеләнгән башка нигезләр буенча билгеле бер чор (ай, квартал, ел) өчен бер тапкыр билгеләнә.

4.11. Мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында»гы Указы белән билгеләнгән максатчан күрсәткечләрнең ирешелгән дәрәҗәсен саклап калу максатыннан төп эш урыны һәм төп вазифа буенча сәламәтлек саклау хезмәткәрләренә, акча булган очракта, бер тапкыр бүләкләү түләве бирелә. Күрсәтелгән максатларда түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме учреждениенең локаль норматив актлары белән билгеләнә.

4.12. Премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләрен башкару күләме, тәртибе һәм шартлары учреждениенең локаль норматив хокукый актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнә.

## V. Компенсация сыйфатындагы түләүләр

5.1. Компенсация сыйфатындагы түләүләргә түбәндәгеләр керә:

- зарарлы һәм (яисә) куркыныч һәм башка махсус хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче сәламәтлек саклау хезмәткәрләренә түләүләр;

- нормаль шартлардан читләшкән шартларда (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазифаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен, төнлә эшләгән һәм нормаль шартлардан читләшкән башка шартларда эшләр башкарганда) эшләгән өчен түләүләр.

5.2. Компенсация сыйфатындагы түләүләр, аларны башкару күләмнәре һәм шартлары хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган хезмәт законнары һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә коллектив шартнамәләр, килешүләр, локаль норматив актлар белән һәм Казан шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләренең хезмәткә түләүнең расланган фонды чикләрендә билгеләнә.

5.3. Зарарлы һәм (яки) куркыныч һәм башка махсус хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче сәламәтлек саклау хезмәткәрләренә компенсация сыйфатындагы түләү ($_{Bkh}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = O_b \times \frac{D_{kh}}{100\%} \times \frac{H_{fk}}{H_n},$$ монда:

$O_b$ – сәламәтлек саклау хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган төп оклады;

$D_{kh}$ – компенсация сыйфатындагы түләүгә өстәмә түләү күләме;

$H_{fk}$ – законнар белән компенсация сыйфатындагы түләүләр карала торган, фактта эшләнгән вакыт, сәгатьләрдә;

$H_n$ – сәламәтлек саклау хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган төп ставка (төп оклад) өчен сәгатьләр нормасы.

Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартларында эшләүче сәламәтлек саклау хезмәткәрләренә эшләгән өчен компенсация сыйфатындагы түләүләр хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә 4 процент күләмендә билгеләнә.

5.4. Нормаль шартларга туры килмәгән шартларда эшләгән өчен (төрле квалификация буенча эшләр башкарганда, һөнәрләрне (вазифаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен, төнлә эшләгән өчен һәм нормаль шартларга туры килмәгән башка шартларда эшләр башкарганда) түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә.



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН